ФГОС

Школьный учебник
«Татарский язык»

КҮҢЕЛЛЕ ТАТАР ТЕЛЕ

Р.З. Хайдарова, Г.М. Ахметзянова, Л.А. Гиниятуллина

# ТАТАР ТЕЛЕ



4 класс
БЕРЕНЧЕ КИСӘК

издательство
«Татармультфильм»





Р.З. Хәйдәрова, Г.М. Әхмәтҗанова, Л.Ә. Гыйниятуллина

# ТАТАР ТЕЛЕ

## ДҮРТЕНЧЕ СЫЙНЫФ

БАШЛАНГЫЧ ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ
ОЕШМАЛАРЫ ӨЧЕН ДӘРЕСЛЕК
(РУС ҺӘМ ТАТАР ТЕЛЛӘРЕНДӘ)

ДӘРЕСЛЕК Е.И.ПАССОВНЫҢ
КОММУНИКАТИВ ТЕХНОЛОГИЯ КОНЦЕПЦИЯСЕНӘ НИГЕЗЛӘНӘ

Ике кисәктә

1 НЧЕ КИСӘК

КАЗАН
«ТАТАРМУЛЬТФИЛЬМ» НӘШРИЯТЫ
2014

Р.З. Хайдарова, Г.М. Ахметзянова, Л.А. Гиниятуллина

# ТАТАРСКИЙ ЯЗЫК

## ЧЕТВЁРТЫЙ КЛАСС

УЧЕБНИК ДЛЯ ОБРАЗОВАТЕЛЬНЫХ ОРГАНИЗАЦИЙ
НАЧАЛЬНОГО ОБЩЕГО ОБРАЗОВАНИЯ
(НА РУССКОМ И ТАТАРСКОМ ЯЗЫКАХ)

НА ОСНОВЕ КОНЦЕПЦИИ КОММУНИКАТИВНОЙ ТЕХНОЛОГИИ
Е.И.ПАССОВА

В двух частях

ЧАСТЬ 1

КАЗАНЬ
ИЗДАТЕЛЬСТВО «ТАТАРМУЛЬТФИЛЬМ»
2014

УДК 811.512.145(075)
ББК 81.632.3я722
Х18

Линейка учебников «Татар теле» («Татарский язык») (1-4 классы) Р.З.Хайдаровой, Н.Г.Галиевой, Г.М.Ахметзяновой, Л.А.Гиниятуллиной издательства «Татармультфильм» входит в **Федеральный перечень учебников**, рекомендуемых к использованию при реализации имеющих государственную аккредитацию образовательных программ начального общего, основного общего, среднего общего образования.

Учебники включены в Федеральный перечень на основании Экспертных заключений:

– Российской академии наук №№001330-001333 от 15.01.2014 г. (педагогическая экспертиза учебников),

– Российской академии наук №10106-5215/283 от 15.10.2013 г. (научная экспертиза учебников),

– НП «Российский книжный союз» от 10.02.2014 г. (общественная экспертиза учебников),

– Министерства образования и науки Республики Татарстан №1865/14–30–33 от 10.02.2014 г. (этнокультурная и региональная экспертиза учебников).

## Условные обозначения

 — начало урока

— запомни

— вспомни

 — обрати внимание

**Хайдарова, Р.З. и др.**

Х18 Татарский язык: учебник для образовательных организаций начального общего образования, в 2-х частях (на русском и татарском языках). / Р.З. Хайдарова, Г.М. Ахметзянова, Л.А Гиниятуллина. — Казань : Татармультфильм, 2014. — 152 с.: ил. — (Татар теле). — ISBN 978-5-906508-01-0.

**ISBN 978-5-906508-01-0**

**УДК 811.512.145(075)**
**ББК 81.632.3я722**

© Издательство «Татармультфильм», 2014
© Художественное оформление
Издательство «Татармультфильм», 2014
Все права защищены




Кадерле укучыбыз!

Менә тагын яңа уку елы башланды. Син дүртенче ел татар теле өйрәнәсең. Син инде татарча укый, яза беләсең, иптәшләрең белән татарча сөйләшә аласың.

Яңа уку елы котлы булсын! Сине Белем көне — Белем бәйрәме белән котлыйбыз, уңышлар телибез!

# Белем бәйрәме




## 1—2 нче дәресләр

**1.** Текстны укы. 1 нче сентябрь нинди көн?

Бүген зур бәйрәм. Яңа уку елы башлана. Укучылар мәктәпкә баралар. Мәктәптә Белем бәйрәме — 1 нче сентябрь. Күңелле музыка уйный. Бар да шат.

**2. Исеңә төшер! Вспомни!**

**Белем бәйрәме** — Праздник знаний
**яңа уку елы** — новый учебный год

**3. Исеңә төшер!** Зурлар, дуслар белән ничек исәнләшәләр һәм хушлашалар?



— Исәнме, Радик!
— Сәлам, Артур!

— Исәнмесез!
— Саумысыз!

— Исәнме, Фәния апа!
— Хәерле иртә, Фәридә апа!
— Хәерле көн, Зөлфия апа!

— Хәерле иртә, Коля!
— Хәерле көн, Наил!



— Хуш, Фәридә!
— Сау бул, Наилә!

— Сау булыгыз!
— Исән булыгыз!

**4.** Бәйрәмдә бер-береңә (друг другу) матур сүзләр әйтәләр. Бу комплиментларның сиңа кайсысы (который) ошый?

— Син бүген бик матур!
— Синең көлмәгең матур!
— Сумкаң нинди яңа!
— Бантигың бик матур!
— Костюм сиңа килешә (подходит)!
— Сиңа бу костюм бик килешә!
— Синең костюмың матур, яңа!

**5.** Укытучыларны Беренче сентябрь бәйрәме белән котларга өйрән.



Хөрмәтле Альбина Галиевна! Сезне Белем көне белән котлыйбыз. Сезгә сәламәтлек, уңышлар телибез.

**6.** Прочитай, выбери понравившийся диалог и разыграй его с соседом по парте.

а) — Исәнме, Радик!
— Сәлам! Хәлләр ничек?
— Рәхмәт, яхшы. Бүген бәйрәм, мин бик шат.
— Мин дә бик шат. Сине бәйрәм белән котлыйм!
— Мин дә сине котлыйм!

ә) — Сәлам, Аня.
— Сәлам, Юля. Син бүген бик матур!
— Әйе, бүген беренче сентябрь, бүген бәйрәм.
— Мин сине бәйрәм белән котлыйм!
— Мин дә сине котлыйм!

## 3—5 нче дәресләр

**1.** Сүзләрнең тәрҗемәсен тап.

әйе

юк

кирәк

бу

түгел

кирәкми

**2.** Уку-язу әсбаплары исемнәрен дөрес әйтергә (правильно произносить) һәм язарга өйрән, алар белән җөмләләр төзе.










**3. Исеңә төшер!**

Частицы **-мы/-ме** в конце слова выражают вопрос: китапмы? дәфтәрме? бармы? кирәкме?

**4.** Используя названия учебных принадлежностей, поговорите друг с другом по образцу.

Образец:

а) — Бу дәфтәрме?
— Әйе, бу дәфтәр.

ә) — Бу дәфтәрме?
— Юк, бу дәфтәр түгел.

б) — Бу дәфтәр яңамы?
— Әйе, бу дәфтәр яңа.

в) — Бу дәфтәр яңамы?
— Юк, бу дәфтәр яңа түгел.

**5. Исеңә төшер!**

**миңа** — мне **сиңа** — тебе **аңа** — ему (ей)

**6.** Дополни диалог, поговори с соседом по парте.

— Сиңа дәфтәр кирәкме?
— ... .
— Сиңа нинди дәфтәр кирәк? Шакмаклы дәфтәрме? Сызыклы дәфтәрме?
— ... .

— Сиңа ничә дәфтәр кирәк?
— ... .

**7.** Используя рисунки:

— попроси себе эти учебные принадлежности;
— сообщи, что тебе нужна тетрадь;
— узнай у друга, нужны ли ему эти учебные принадлежности.




**8. Исеңә төшер!**

В татарском языке имя существительное при числительных употребляется в единственном числе: **өч алма, биш дәфтәр, дүрт карандаш.**

**9.** Җөмләләрне киңәйтеп (распространив) яз. Һәр җөмләгә сорау куй.

Үрнәк: Китап бар. Сумкада китап бар. Сумкада 3 китап бар.

Җөмләләр: Дәфтәр бар. Көндәлек бар. Бетергеч бар.

**10.** Нокталар урынына (вместо точек) төшеп калган репликаларны яз.

— … ?
— Юк, миңа дәфтәр кирәкми.
— Ә нәрсә кирәк?
— … .

## 6—7 нче дәресләр

**1. Исеңә төшер!**

мой(я) — **минем** (китабым, көндәлегем)
твой(я) — **синең** (китабың, көндәлегең)
его (её) — **аның** (китабы, көндәлеге)

В словах, оканчивающихся на **к**, **п**, при добавлении аффиксов **-ым/-ем**, **-ың/-ең**, **-ы/-е** звуки **[к]**, **[қ]** и **[п]** чередуются со звуками **[г]**, **[ғ]** и **[б]**:

көндәле**к** — көндәле**г**ем, күлмә**к** — күлмә**г**ем, урынды**к** — урынды**г**ым, ту**п** — ту**б**ым.

**2.** Рәсемнәр урынына тиешле сүзләрне куеп укы.

1. Бу минем . 2. Синең  бармы? 3. Оляның  яңамы? 4. Минем яңа  бар. 5. Синең  бармы? 6. Коляның  бармы?

**3.** Синең уку-язу әсбапларың бармы? Иптәшеңнән сора: аның нинди уку-язу әсбаплары бар?

**4.** **Исеңә төшер!**

**-лар/-ләр, -нар/-нәр** — аффиксы множественного числа:

китап — китап**лар**,
дәфтәр — дәфтәр**ләр**,
урман — урман**нар**,
көн — көн**нәр**.

**5.** Шигырьне укы, ошаса, ятла.

Һәр атнада җиде көн,
Җиде көн һәм җиде төн,
Портфельдә җиде әйбер,
Ул нинди әйберләр бел:
Карандаш һәм бетергеч,
Дәфтәр, каләм, киптергеч,
Бер агач пенал тагы
Һәм әлифба китабы.

Самуил Маршак

**6.** Диалогны репликалар өстәп укы. Иптәшең белән сөйләш.

— Исәнме, Оля!
— ... .
— Оля, синең сумкаң бик матур, яңамы?
— Әйе, минем сумкам яңа, апам бүләк итте.
— ... ?
— Әйе, мин 10 яңа дәфтәр, 1 көндәлек алдым.
— ... .



**7.** Как скажешь о том, что:

— тебе купили ручку, тетради, дневник;
— сумку подарила твоя сестра;
— ты учишься в четвёртом классе;
— ты поздравил учителя с новым учебным годом;
— у тебя в сумке 5 тетрадей, 2 книги?

## 8—9 нчы дәресләр

**1. Исеңә төшер!**

В татарском языке 9 гласных и 28 согласных звуков.

Гласные [а] — [ә], [у] — [ү], [ŏ] — [ө], [ы] — [ э̆] — парные по твёрдости и мягкости, [и] — всегда мягкий звук. В татарском языке есть звуки, которых нет в русском. Это — [қ], [ғ], [w], [ң], [җ], [h], [а°], [ә], [ү], [ŏ], [ө], [ы̆], [э̆].

**2.** Бу авазлар ничек әйтелә?

[а] — огублённно — каты — [қа°ты́]
[қ] — твёрдо — калын — [қа°лы́н]
[ғ] — твёрдо — чыга — [чы̆ға́]
[ы̆] — кратко — авыл — [а°wы́л]
[э̆] — кратко — бетергеч — [бэ̆тэ̆ргэ́ч]
[ŏ] — кратко — болын — [бŏло́н]

**3.** Ничек укыла?

е:
[йы] — елан
[йэ̆] — егет
[э̆] — беренче

я:
[йа°] — яза
[йә] — яшел

**4.** Җөмләләрдәге сүзләрне транскрипция билгеләре белән яз. Текстны укы, партадашыңа сөйлә.

Яңа уку елы башланды. Без тагын мәктәпкә килдек. Бүген мәктәптә зур бәйрәм. Без укытучыларны яңа уку елы белән котладык. Аларга чәчәкләр бирдек.

**5. Исеңә төшер!**

**к, г** хәрефләре ике аваз белдерә:

**к** — [қ] — кара; [к] — кил

**г** — [ғ] — карга; [г] — гөл

**6.** Шигырьне укы.

**К хәрефен белегез, к ны дөрес әйтегез**

**К** хәрефен кем күрде?
**К** кайда бар, кем белде?
— Кайда да бар икән,
Кырда, калада икән,
**К** куян колагында,
**К** кошлар канатында.
Кем оннан камыр изә,
Аннан күмәч пешерә,
Кем җәй көймәдә йөзә,
Көзен кәбестә кисә —
Шул кеше **к** ны күрә.

Хәләф Гарданов

**икән** — оказывается
**кала (шәһәр)** — город
**кисә** — режет
**канат** — крыло
**камыр** — тесто
**кыр** — поле

**7.** Шигырьдән **к** хәрефе кергән сүзләрне тап, таблицага яз.

| [ķ] | [к] |
|---|---|
| кара<br>... | кил<br>... |

**8.** Сүзләрне транскрипция билгеләре белән яз. Дөрес әйтергә өйрән.

Колак, куян, кыр, ком, канат, күмәч, чәчәк, камыр, көймә, кәбестә, кисә, күрә.

**9.** Шигырьне сәнгатьле укырга өйрән. Ошаса, ятла.

## 10—11 нче дәресләр

**1. Исеңә төшер!**



**О, ы, э** хәрефләре икешәр аваз белдерә.

Рус теленнән кергән сүзләрдә алар сузыбрак әйтелә:

[пасы̄лка], [вы̄шка], [шты̄к], [э̄таж].

Татар сүзләрендә алар кыска әйтелә:

[то̆р], [ы̆лы́с], [йо̆рт], [э̆т].

**2.** Сүзләрне таблицага яз.

Кыш, йокы, орден, оя, посылка, кино, эш, кырык, завод, болын, экран, флот, калын, радио, орлык, солдат, йорт, солы, озын, кыска, почта, эт, котлый.

| [о ō], [ы̄], [э̄] | [ŏ], [ы̆], [э̆] |
|---|---|
| ... | ... |

**3.** Җөмләләрдәге сүзләрне транскрипция билгеләре белән яз, дөрес укы.

1. Менә көз җитте. 2. Кошлар җылы якка китәләр. 3. Безнең йорт янында почта бар. 4. Безгә Мәскәүдән посылка килде. 5. Без кырыгынчы йортта торабыз.

**4. Исеңә төшер!**



**О, ө** хәрефләре татар сүзләренең беренче иҗегендә генә языла: **олы, болыт, көчле, төлке.**

**5.** Нокталар урынына тиешле хәрефләрне куеп яз.

Көзг..., ...стәл, Р...стәм, төлк..., сөлг..., бол...т, оз...н.

**6. Исеңә төшер!**

Татар телендә **ң** хәрефенә башланган сүз юк, **ң** хәрефе сүз уртасында (в середине) яки ахырында (в конце) гына килә:

**аңа** — ему, **таң** — рассвет.

7. Шигырьне укы. **ң** хәрефе нигә кайгыра?

**Үсми калган хәреф**



Йөри, ди, **ң** каңгырып,
Йөри, ди, ул кайгырып.
Эшләре аның яман —
Үсеп җитми, ди, һаман
Сүз башында торырга
Һәм баш хәреф булырга!

Роберт Миңнуллин

**каңгырып йөри** — блуждает, бродит
**кайгырып йөри** — печалится
**эшләре яман** — дела плохи

8. Спроси у друга:

— сколько букв в татарском языке;

— сколько согласных, сколько гласных звуков;

— каких татарских звуков нет в русском языке.

**9.** Бергәләп көлик. Посмеёмся вместе.



Укытучы дәрестә бер малайга авазлар турында сөйләргә кушкан. Малай:

— Тартыклар: б, в, г, д, ж. Сузыклар: а, ә, ү, у, я... — дип туктаган.

— Ә калганнар (остальные)?

— Калган авазлар тартылмый да, сузылмый да, — дигән малай.

## 12—13 нче дәресләр

3 4 5 7 2 9 6 10 8 1

**1.** Саннарны тәртип буенча урнаштыр (расположи по порядку).

1. Бер, өч, ике, алты, дүрт, биш, җиде, ун, тугыз, сигез.

2. Унике, унбер, ундүрт, егерме, унбиш, унҗиде, унтугыз, унсигез, унөч, уналты.

**2.** Саннарны сүз белән яз, җөмләләр төзе.

10, 20, 30, 40, 50, 60, 70, 80, 90, 100

**3. Исеңә төшер!**

**ничә?** — сколько? — биш, алты
**ничәнче?** — который (по счёту)? — бишенче, алтынчы
**ничәү?** — сколько? — бишәү, алтау

**биш, алты, ...** — количественные (микъдар) числительные
**бишенче, алтынчы, ...** — порядковые (тәртип) числительные
**бишәү, алтау, ...** — собирательные (җыю) числительные

**4.** Укы. Саннарга сорау куй. Алар нинди саннар?

Берәү,
Икәү,
Өчәү,
Дүртәү...
Санарга өйрәнәбез.

Роберт Миңнуллин

**5. Исеңә төшер!**

**кушарга** — прибавить
**алырга** — вычитать
**мәсьәлә** — задача
**тапкырларга** — умножить
**бүлергә** — делить
**мисал** — пример

Мин мисалны чиштем, ә мәсьәләне чишмәдем.

**6.** Мисалларны чиш, татарча әйт.

4+4=?
6+4=?
8–2=?
10–4=?

**7.** Скажи:

— сколько тебе лет;
— в какой школе ты учишься;
— в каком ряду ты сидишь;
— сколько мальчиков и девочек в классе;
— что тебе надо пять тетрадей в клетку и пять тетрадей в линейку.

**8.** Какой вопрос задашь, чтобы узнать:

— в каком классе учится Марат;
— в каком ряду сидит Марат;
— нужны ли Марату тетради, книги?

**9.** Мәсьәләне чиш.

Синең 6 дәфтәрең бар. Син 2 дәфтәреңне Алмазга бирдең. Ничә дәфтәрең калды?



## 14—15 нче дәресләр

**1.** **Исеңә төшер!**

**чөнки** — потому что
**шуңа күрә** — поэтому

**2.** Сүзләрне дөрес укырга өйрән. Тәрҗемә ит.

[бә̆тә̆ргә́ч], [кирәклә́], [һә́рwақы̆т], [сүндә̆рә́м], [өстөнә́], [қәлә́м], [тәрти́п].

**3.** Текстны укы. Оляның эш урыны сиңа ошыймы?

### Эш урыны



Минем исемем — Оля. Мин дүртенче сыйныфта укыйм. Мин тәртип яратам, шуңа күрә эш урыным һәрвакыт чиста. Минем эш урыным — язу өстәле.

Өстәлдә бары тик кирәкле китаплар, дәфтәрләр генә бар. Өстәлгә каләм, линейка, бетергеч тә куям. Алар һәрвакыт кирәк. Өстәл өстенә ваза белән чәчәк куям, чөнки мин чәчәк яратам.

**4.** Бу сүзләр кергән җөмләләрне тексттан табып укы. Аларның тәрҗемәсен беләсеңме?

| | | |
|---|---|---|
| тәртип | һәрвакыт | кирәк |
| эш урыны | куям | сүндерәм |

**5.** Найди в тексте предложения о том, что:

— Оля учится в четвёртом классе;
— Оля любит порядок;
— Оля любит цветы;
— рабочее место Оли — письменный стол.

**6.** Рәсемгә кара һәм әйт: эш өстәлендә нәрсәләр артык (лишнее)?



**7.** Бу предметларның кайсысы Оляның өстәлендә юк?

Көндәлек, китап, плеер, компьютер, төсле карандашлар, бетергеч, пенал, ваза, магнитофон, альбом, портфель, стакан.

**8.** Диалогларны укы. Дустың белән сөйләш.

1. — Синең эш урының бармы?
— Әйе, бар.
— Ул кайда?
— Бүлмәдә.

2. — Өстәлең нинди чиста!
— Әйе, мин тәртип яратам.
— Ә сумкаң кайда?
— Урындыкта.

3. — Оля, миңа бетергеч бир әле.
— Ал.
— Ә кайда ул?
— Пеналда.

4. — Саша, син нишлисең?
— Дәрес әзерлим.
— Кайсы предметтан?
— Математикадан.

5. — Син эш урынына нәрсәләр куясың?
— Эш урынына кирәкле әйберләрне куям.

**9.** Уйла һәм әйт: яхшы уку өчен, кайсы сыйфатлар кирәк?

Тырыш, игътибарлы, ялкау, игътибарсыз, эшчән, тәртипле, тәртипсез.

**10.** Җөмләләрне тәгәллә һәм дәфтәреңә яз. Аларга сорау куй.

1. Оля — тырыш укучы, шуңа күрә ... .
2. Сашаның өстәле һәрвакыт ... , чөнки ул тәртип ... .
3. Укучы дәрестә игътибарсыз, шуңа күрә ул ... .
4. Наташаны дуслары ярата, чөнки ул ... .

**11.** Узнай у друга:

— есть ли у него дома рабочее место;
— что есть у него на рабочем столе.



**12.** Бергәләп көлик.

Укытучы:
— Фәрит, математикадан өй эшен нигә эшләмәдең?
Укучы:
— Әти күзлек тапмады.

**күзлек** — очки
**тапмады** — не нашёл

## 16—17 нче дәресләр

**1.** Сүзләрнең тәрҗемәсен исеңә төшер.

| | |
|---|---|
| пример | упражнение |
| задача | контрольная работа |
| вопрос | ответ |

**2.** Составь словосочетания из слов в столбиках.

мисал
мәсьәлә
контроль эш
җавап
сорау
күнегү
диктант

?

чиштем
бирдем
яздым
әйттем
эшләдем

**3.** Диалогларны укы, дустың белән сөйләш.

а) — Оля, бу нинди дәрес?
— Бу — татар теле дәресе.
— Сез дәрестә нишлисез?
— Без укыйбыз, күнегү эшлибез, диктант язабыз.

ә) — Костя, бу нинди дәрес?
— Бу — математика дәресе.
— Сез дәрестә нишлисез?
— Без дәрестә мисал эшлибез, мәсьәлә чишәбез.

**4. Исеңдә калдыр!**

**хаталы** — с ошибкой
**хатасыз** — без ошибок
**математика** — математика
**математикадан** — по математике
**математикадан контроль эш** — контрольная работа по математике
**математика дәресендә** — на уроке математики
**татар теле** — татарский язык
**татар теленнән** — по татарскому языку
**татар теле дәресендә** — на уроке татарского языка

**5.** Как ты спросишь у друга:

— приготовил ли он домашнее задание;
— что задано на дом;
— какие оценки он получил сегодня;
— какие уроки ему нравятся;
— правильно ли он решил задачу?

**6.** Восстанови диалог, поговори с соседом по парте.

— ... ?
— Мин математикадан «дүрт»ле алдым. Ә син?
— ... .
— ... ?
— Юк, татар теленнән диктант язмадык, иртәгә язабыз.
— Без дә иртәгә язабыз.
— Син куркасыңмы?
— ... .
— Мин дә курыкмыйм, чөнки татар телен яхшы беләм.

**7. Исеңә төшер!**

**Сәгать ничә?** — Который час?
**Сәгать ничәдә?** — Во сколько часов?
**сәгать алты** — шесть часов
**сәгать алтыда** — в шесть часов
**сәгать алтынчы яртыда** — в половине шестого

**8.** Рәсемгә кара һәм әйт: сәгать ничә?



**9.** Спроси у друга:

— во сколько часов он встаёт утром;
— делает ли он зарядку;
— во сколько часов начинаются уроки в школе.

## 18—19 нчы дәресләр

**1. Бу сүзләрне исеңдә калдыр!** Алар белән җөмләләр төзе.

**кәефсез** — без настроения
**кичә** — вчера
**бугай** — кажется
**башта** — вначале
**озак** — долго
**аннан соң** — потом

**2.** Җөмләләрне үрнәк буенча киңәйтеп (распространив) яз.

Үрнәк: Без мәсьәлә чиштек. Без бүген мәсьәлә чиштек. Без бүген математика дәресендә мәсьәлә чиштек.

Җөмләләр: Без мисал чиштек. Без диктант яздык.

**3.** Хикәяне укы һәм исем бир.



Бүген Алсу мәктәптән кәефсез кайтты. Өченче дәрестә контроль эш булды. Ә Алсу ике мисалны дөрес эшләмәде, мәсьәләне дә дөрес чишмәде. Ул контроль эш икәнен белде, ләкин әзерләнмәде. Кичә бик озак телевизор карады. Башта мультфильм, аннан соң кызыклы кино булды. Аннан дуслары килде. Алар белән дә күңелле булды. Кичә күңелле иде, ә бүген...

**4.** Бу җөмләләрнең кайсысы текстта бар?

1. Бишенче дәрестә математикадан контроль эш булды. 2. Өченче дәрестә татар теленнән язма эш булды. 3. Өченче дәрестә математикадан контроль эш булды. 4. Ике мисалны дөрес эшләмәде. 5. Мәсьәләне дөрес чиште. 6. Мәсьәләне дөрес чишмәде. 7. Дуслар белән күңелле булды. 8. Алар белән дә күңелле булды. 9. Кичә дә, бүген дә күңелле булды. 10. Кичә күңелле булды, ә бүген күңелсез.

**5.** Җөмләләрне текст эчтәлеге тәртибендә урнаштыр.

Өченче дәрестә математикадан контроль эш булды. Алсу мәсьәләне дөрес чишмәде. Алсу ике мисалны дөрес эшләмәде. Аннан соң дуслары килде. Башта мультфильм, аннан кызыклы кино булды. Алсу озак телевизор карады.

**6.** Ике раслауның кайсысы дөрес?

1. — Татар теленнән контроль эш булды.
   — Математикадан контроль эш булды.
2. — Алсу мисалны дөрес эшләде.
   — Алсу мисалны дөрес эшләмәде.
3. — Алсу мәсьәләне дөрес чиште.
   — Алсу мәсьәләне дөрес чишмәде.

**7.** Җөмләләрне дәвам ит.

1. Өченче дәрестә ... . 2. Алсу ике мисалны ... һәм мәсьәләне ... . 3. Алсу бик озак ... . 4. Телевизордан башта ... , аннан соң ... . 5. Ул дәресләрен ... .

**8.** Сообщи другу о том, что:

— сегодня у вас пять уроков;

— на втором уроке была контрольная работа по математике;

— во вторник вы писали диктант по татарскому языку;

— сегодня ты учишь стихотворение;

— он неправильно решил задачу;

— он правильно решил примеры;

— в гостях было весело.

**9.** Восстанови диалоги, поговори с соседом по парте.

1. — ... ?
   — Бездә контроль эш булды.
   — Кайсы предметтан?
   — ... .
2. — ... ?
   — Юк, мин дәрес әзерләмәдем.
   — Нәрсә эшләдең?
   — ... .

## 20—21 нче дәресләр

**1.** Алсу турындагы хикәяне искә төшер. Иң яхшы сөйләүчегә конкурс! Сөйләүчегә бәя бирергә онытма!

| **Эчтәлекне ничек сөйли?** | **Сүзләрне ничек әйтә?** |
|---|---|
| Эчтәлекне дөрес сөйли. | Сүзләрне дөрес әйтә. |
| Эчтәлекне дөрес сөйләми. | Сүзләрне дөрес әйтми. |

**Ничек сөйли?**

Сәнгатьле сөйли.
Сәнгатьле сөйләми.

**2.** Представь, что Алсу не ленилась, готовила уроки. Изменится ли рассказ? Напиши его. Перескажите друг другу свои рассказы.

**3.** Беренче һәм икенче хикәядәге Алсуга кайсы сыйфатлар туры килә? Таблицаны тутыр.

| Беренче хикәядәге Алсу | Икенче хикәядәге Алсу |
|---|---|
| ... | ... |

**4.** Бу диалогларның кайсысы текстка туры килә? Партадашың белән сөйләш.

1. — Алсу, әйдә мультфильм карыйбыз!
— Ярый, кызлар, безгә килегез.
— Бүген кызыклы кино була.
— Кино да карыйбыз.

2. — Алсу, әйдә урамга чыгабыз.
— Юк, чыкмыйм, эшем бар.
— Нишлисең?
— Иртәгә математикадан контроль эш була. Әзерләнәм.

**5.** Как скажешь о том, что:

— завтра у вас контрольная работа по математике;
— сегодня вы писали диктант по русскому языку;
— ты написал диктант без ошибок?

**6.** Восстанови диалоги. Поговори с соседом по парте.

1. — ... ?
— Әйе, контроль эш булды.
— Ничә мисал бар иде?
— ... .
— ... ?
— Әйе, мәсьәлә дә бар иде.
— Ничә?
— ... .

2. — ... ?
— Әйе, контроль эш булды.
— Контроль эшне эшләдеңме?
— ... .
— Ә мәсьәләне чиштеңме?
— ... .



**7. Исеңә төшер!**



**кебек** — как, словно
**турында** — о, про
**бит** — 1) лицо; страница 2) ведь
**ярамый** — нельзя

8. Бергәләп көлик.



Укытучы Галинең хикәясен укыды да:

— Синең хикәяң нәкъ Вәлинеке кебек бит. Күчердеңме? — диде.

— Мин күчермәдем. Без бер бүре турында (об одном и том же волке) яздык, — диде Вәли.

**күчердеңме** — списал

## 22—23 нче дәресләр



1. Габдулла Тукай турында искә төшер. Син аның нинди шигырьләрен хәтерлисең?

Габдулла Тукай — татар халкының бөек шагыйре. Габдулла Тукай исемен һәркем белә. Ул зурлар өчен дә, кечкенәләр өчен дә бик күп шигырьләр язган. Аның шигырьләрен бик яратып укыйлар.

**2.** Прочитай стихотворение Г. Тукая. Чем отличаются отношения мальчика и Алсу к урокам?

### Сабыйга

Бик матур бер җәйге көн: өстәл янында бер Сабый
Ян тәрәзә каршысында иртәгесе дәресен карый.

Шул чагында бу Сабыйны чакыра тышка Кояш:
«И Сабый, ди, әйдә тышка, ташла дәресең, күңелең ач!»

Бу Кояшның сүзенә каршы җавабында Бала:
«Тукта, сабыр ит, уйнамыйм, ди, уйнасам, дәресем кала».

Өй түрендә шул заман сайрый ботакта Сандугач,
Ул да шул бер сүзне сайрый: «Әйдә тышка, күңелең ач!»

Сандугачка каршы биргән җавабында Бала:
«Юк, сөекле Сандугачым, уйнасам, дәресем кала».

Шул вакытта өй түрендә бакчада бер Алмагач
Чакыра тышка Сабыйны: «Әйдә тышка, күңелең ач!»

Алмагачның сүзенә каршы җавабында Бала:
«Юк, сөекле Алмагачым, уйнасам, дәресем кала».

Күп тә үтми, бу Бала куйды тәмамлап дәресен,
Куйды бер читкә җыеп дәфтәр, китапны — барысын.

Чыкты йөгереп бакчага: «Йә, кем чакырды, дип, мине?
Әйдә, кем уйный? Тәмам иттем хәзер мин дәресемне».

Шунда аңа бик матурлап елмаеп көлде Кояш,
Шунда аңа кып-кызыл, зур алма бирде Алмагач;

Шунда аңа шатланып сайрап җибәрде Сандугач,
Шунда аңа баш иделәр бакчада һәрбер агач.

**күңелең ач** — веселись
**сабыр ит** — потерпи
**дәресем кала** — урок остаётся
**шул заман** — здесь: в это время
**куйды тәмамлап дәресен** — закончил готовить уроки
**тәмам иттем** — закончил
**куйды бер читкә җыеп** — собрал в одно место
**баш иделәр** — преклонились
**сөекле** — любимый
**сайрый** — здесь: поёт

**3.** Рәсемгә туры килгән җөмләләрне шигырьдән табып укы.



**4.** Җөмләләрне дәвам ит.

«Әй Сабый, әйдә урамга чык», — ди ... .
«Юк, чыкмыйм, мин дәрес әзерлим», — ди ... .
«Әйдә тышка, күңел ач!» — ди ... .
«Минем дәресем тәмам, кем уйный?» — ди ... .

**5.** Рәсемгә кара һәм әйт: Сандугач, Кояш, Алмагач Сабыйга ничек сөенделәр (как обрадовались)?



**6.** Шигырьнең эчтәлеген сөйләргә әзерлән, текстны дәвам итеп, дәфтәреңә яз.

Малай дәрес әзерли. Кояш Сабыйны тышка чакыра. «Мин уйнамыйм, дәрес әзерлим», — ди Сабый. ...

**7.** Алсуга һәм Сабыйга бу сыйфатларның кайсысы туры килә? Таблицага яз.

| Алсу | Сабый |
|---|---|
| ... | ... |

Тырыш, эшчән, игътибарлы, онытучан, игътибарсыз, ялкау, яхшы, тәртипсез, тәртипле.

## 24—25 нче дәресләр

### Проверь себя!

**1.** Сколько букв, сколько звуков есть в татарском языке?

**2.** а) Назови татарские звуки, которых нет в русском языке.

б) Какая буква в татарском языке не может быть заглавной?

**3.** Сүзләр ничек әйтелә? Транскрипция билгеләре белән яз.

Белем, яңа, уку, котлый, каләм, бетергеч, яңгыр, китапханә, сөлге, төтен, төлке, олы, болын, колын.

**4.** Приведи примеры с порядковыми, собирательными числительными и составь с ними предложения.

**5.** Спроси у соседа по парте:

— какие учебные принадлежности у него есть;
— как прошёл День знаний в школе;
— какие оценки он уже получил;
— какие уроки ему нравятся.

**6.** Сорауларга җавап бир.

1. Син ничәнче мәктәптә укыйсың? 2. Син ничәнче сыйныфта укыйсың? 3. Син нинди телләр өйрәнәсең? 4. Татарча яхшы беләсеңме? 5. Татар теле дәресендә син нәрсәләр эшлисең? 6. Математика дәресендә нәрсә чишәсең? 7. Рәсем дәресендә һәм җыр дәресендә нишлисез?

**7.** Какие вопросы ты задашь, чтобы получить такие ответы?

— ... ?
— Юк, без диктант яздык.
— ... ?
— Мин «дүрт»ле алдым.
— ... ?
— Ике хатам бар.
— ... ?
— Юк, урамга чыкмыйм, мин дәрес әзерлим.

**8.** Нинди мәзәкләрне истә калдырдың? Берсен иптәшеңә сөйлә.

**9.** Сообщи другу о том, что:

— ты учишься в четвёртом классе;
— вы ходите в школу вчетвером;
— в семье вас четыре человека;
— ты живёшь на седьмом этаже.

**10.** Нокталар урынына тиешле хәрефләрне куй.

а) к...л...н
б...л...н
б...л...т

ә) җи...
җи...
җи...

**11.** Монда нинди сүз язылган?



# ТУГАН ЯК ТАБИГАТЕ

## 26—28 нче дәресләр



**1.** Шигырьне укы. Нәрсә ул табигать?

### Табигать китабы

Әйдәгез урманга
Һәм кырга —
Табигать китабын
Укырга.
Бу китап гаять зур,
Гаять бай.
Анда бар:

Җир, су, күк,
Кояш, ай.
Йөрибез урманда,
Аланда,
Җәнлекләр,
Кош-кортлар
Күп анда...

Җәвад Тәрҗеманов

**табигать** — природа
**алан** — поляна
**гаять** — очень
**кош-корт** — птицы

**2.** Рәсемгә кара һәм дустыңа сөйлә: нәрсә ул табигать?

**3.** Текстны укы. Елның нинди фасыллары бар?

## Елның дүрт фасылы

Ел дүрт фасылга бүленә: яз, җәй, көз, кыш.
Яз айлары: март, апрель, май.
Җәй айлары: июнь, июль, август.
Көз айлары: сентябрь, октябрь, ноябрь.
Кыш айлары: декабрь, гыйнвар, февраль.

Бу айларның кайсысы утыздан, кайсысы утыз бер көннән килә, ә февраль ае гына 28—29 көннән килә.

Габдулла Тукайдан

**4.** Рәсемнәр кайсы ел фасылына туры килә?



**5. Исеңдә калдыр!**



**табигать** — природа
**саргая** — желтеет
**озын** — длинный
**озыная** — становится длиннее
**коела** — падает
**иң** — самый

**6.** Бу сүзләр ничек укыла? Транскрипция билгеләре белән яз. Җөмләләр төзе.

Кошлар, агачлар, яфраклар, җылы як, яшел, саргая, чыршы, нарат.

**7.** 6 нчы күнегүдәге сүзләрне яза беләсеңме? Иптәшеңә диктант яздыр.

**8.** Җөмләләргә сорау куй. Сорау-җавап формасында (в форме вопроса-ответа) иптәшең белән сөйләш.

1. Көз көне яфраклар саргая, коела, ә чыршы белән нарат яшел калалар.
2. Бүген иң матур көн.
3. Көз көне төннәр озыная, көннәр кыскара.



**9.** **Исеңә төшер!**

**Үткән заман хикәя фигыль**
**Прошедшее время глагола**

К основам глагола, оканчивающимся на гласные и звонкие согласные звуки, в прошедшем времени присоединяются аффиксы **-ды/-де: аша-ды, кил-де.**

К основам глагола, оканчивающимся на глухие согласные, в прошедшем времени присоединяются аффиксы **-ты/-те: кайт-ты, кит-те.**

**10.** Җөмләләрне укы. Калын хәрефләр белән бирелгән фигыльләрнең заманын билгелә һәм таблицага яз.

Көз **житте**. Көннәр салкын. Салкын җил **исә.** Кошлар җылы якларга **китә.** Агачлар яфракларын **коя**. Көннәр **кыскарды**, төннәр **озынайды.** Мәктәптә укулар **башланды.**

| Үткән заман хикәя фигыль | Хәзерге заман хикәя фигыль |
|---|---|
| ... | ... |

**11.** Җөмләләрне дәвам ит.

1. Көннәр салкын, чөнки ... . 2. Көннәр кыска, төннәр озын, чөнки ... . 3. Көз җитте, шуңа күрә ... . 4. Кошлар җылы якка китте, чөнки ... .

**12.** Спроси у друга:

— нравится ли ему осень;
— куда улетают птицы;
— какая бывает погода осенью;
— когда начнутся осенние каникулы.

**13.** Диалогны укы. Партадашың белән сөйләш.

— Айдар, әйдә урманга барабыз.
— Ә көн нинди?
— Салкын түгел, җылы.
— Урманда нишлибез?
— Яфраклар җыябыз.

**14.** Восстанови диалог. Разыграй его с соседом по парте.

— ... ?
— Юк, мин урамга чыкмыйм.
— ... ?
— Чөнки көн бик салкын.
— Урамда салкын, ләкин җил юк.
— ... ?
— Әйе, малайлар урамда. Футбол уйныйлар. Чыгасыңмы?
— ... .

**15.** Табышмакның җавабын тап.

Кулсыз, аяксыз — тәрәзә кага (стучит).

## 29—30 нчы дәресләр

**1.** Рәсемнәргә кара, җөмләләр төзе.









... ява.
... оча.

... исә.
... туңды.

**2.** Кайсы җөмләләрдә көз билгеләре юк?

1. Агач яфраклары саргайды. 2. Сулар туңды. 3. Кояш кыздыра. 4. Яфраклар коелалар. 5. Кошлар җылы якка китә. 6. Җылы яңгырлар башлана. 7. Салкын җил исә. 8. Көннәр җылына.

**3. Исеңдә калдыр!**

**һава торышы турында** — о погоде
**җил төньяктан** — ветер с севера, ветер северный
**җил көньяктан** — ветер с юга, ветер южный
**явымсыз** — без осадков
**болытлы** — облачно

**4.** Әйтик, син диктор. Һава торышын әйтергә өйрән.




Бүген унынчы октябрь. Көн болытлы. Кар ява. Җил төньяктан.

Төнлә Казанда температура минус 2°С, минус 3°С, көндез плюс 1°С, плюс 2°С.

**5.** Уйла һәм әйт: бу һава торышы кайсы ел фасылына туры килә?

1. Көн эссе, явымсыз, көндез температура плюс 30°С, төнлә плюс 20°С.
2. Көн болытлы, кар, урыны белән буран. Җил төньяктан. Температура минус 22°С.

**6.** Җәйге, язгы, кышкы бер көнгә һава торышын яз.

**7.** Рәсемнәр урынына сүзләр куй. Иптәшең белән сөйләш.

— Әйдә урманга барабыз.
— Нәрсәгә?
—  җыярга.
— Юк, мин бармыйм.
— Нигә?
— Мин һава торышын тыңладым.
— Һава торышы нинди?
—  була.

**8.** Шигырьне укы, ошаса, ятла.

**Көз һәм балалар җыры**

— Көз, көз, әйт әле,
Кәрзинеңдә ниләр бар?
— Кәрзинемдә кыярлар,
Помидор һәм алмалар.
— Көз, көз, әйт әле,
Кәрзинеңдә ниләр бар?
— Кәрзинемдә яңгырлар,
Җылы-суык көннәр бар.
— Көз, көз, әйт әле,
Кәрзинеңдә ниләр бар?
— Әбиемә, бабама
Күчтәнәчләр, бүләкләр.

Г. Гәрәева

## 31—32 нче дәресләр

**1. Исеңә төшер!**

| Сораулар / Авазлар | кая? | кайда? | кайдан? |
|---|---|---|---|
| Сузыклар калын | **-га** | **-да** | **-дан** |
| нечкә | **-гә** | **-дә** | **-дән** |
| Тартыклар | | | |
| яңгырау | **-га, -гә** | **-да, -дә** | **-дан, -дән** |
| саңгырау | **-ка, -кә** | **-та, -тә** | **-тан, -тән** |
| [н], [м], [ң] | **-га, -гә** | **-да, -дә** | **-нан, -нән** |

**2.** Җөмләләр төзе.

Мин — зоопарк / урман / мәктәп / китапханә ? -га / -гә / -ка / -кә — барам.

**3. Исеңә төшер!**

| | |
|---|---|
| Мин бара + **м.** | Без бара + **быз.** |
| Син бара + **сың.** | Сез бара + **сыз.** |
| Ул бара. | Алар бара + **лар.** |

**4.** Уточни:

— идёт ли Марат в аптеку, в лес, в школу;
— идут ли друзья в аптеку, в лес, в школу.

**5.** Текстны укы. Син нинди дару үләннәрен беләсең?

## Дару үләннәре

Безнең туган ягыбызда зур урманнар, киң болыннар бар. Урманнарда дару үләннәре күп. Дару үләннәре сәламәтлек өчен файдалы. Без бака яфрагы, мәтрүшкә, кычыткан җыйдык. Дару үләннәрендә витаминнар күп.

**6.** Хикәядән дару үләннәренең исемнәрен тап, дәфтәреңә яз һәм тәрҗемә ит.

**7.** Дару үләннәренең исемнәрен дөрес укыйсыңмы?

[ба°қá йа°фрағы́], [үги а°нá йа°фрағы́], [қы̆чы̆тқáн].

**8.** Рәсемнәргә карап, дару үләннәренең исемнәрен әйт, җөмләләр төзе.



**9.** Диалогларны укыгыз, сөйләшергә өйрәнегез.

1. — Оля, син кая барасың?
— Даруханәгә. Әбием авырый.
— Нинди дару аласың?
— Мин дару алмыйм, дару үләне алам.

2. — Алсу, син нинди дару үләннәрен беләсең?
— Мәтрүшкә, кычыткан, бака яфрагы.
— Сезнең өйдә дару үләннәре бармы?
— Әйе, җәй көне әбием белән җыйдык.

**10.** Спроси у друга, какие лекарственные травы он знает.

## 33—34 нче дәресләр

**1. Исеңә төшер!**

| | |
|---|---|
| **кемне** — кого? | **нәрсәне?** — чего? что? |
| әнине | кышны |
| әтине | урманны |
| бабайны | өйне |

**2.** Сорауларга җавап бир, җөмләләрне укы.

Мин (нәрсәләрне?) чәчәкләр... әнигә бирәм.
Мин (кемне?) әти... , әни... бик яратам.

**3.** Үрнәктәгечә яз, сүзләр белән җөмләләр төзе.

Үрнәк: нәрсәне? — урман-ны
Мәтрүшкә, үлән, дару, кычыткан.

**4.** Какие вопросы ты задал бы, чтобы получить такие ответы?



— ... ?
— Без урманда, болында булдык.
— ... ?
— Дару үләннәре җыйдык.
— ... ?
— Әйе, күп җыйдык.
— ... ?
— Мәтрүшкә, ромашка җыйдык.

**5.** Җөмләләрне дәвам ит.

1. Дару үләннәре безгә кирәк, чөнки ... .
2. Дару үләннәре күп, ләкин ... .
3. Дару үләннәре файдалы, шуңа күрә ... .
4. Дару үләннәрен җыйдык, ләкин ... .

**6.** Диалогны укы. Дустың белән сөйләш.

— Дима, әйдә даруханәгә барабыз.
— Нәрсәгә?
— Дару алабыз.
— Кем авырый?
— Әбием.
— Бездә дару үләннәре күп. Әйдә безгә. Мин сиңа дару үләннәре бирәм.
— Рәхмәт.

**7.** Рәсемнәрнең исемнәрен таблицага яз.

| Агачлар | Дару үләннәре | Яшелчәләр | Җиләк-җимешләр |
|---|---|---|---|
| ... | ... | ... | ... |



## 35—36 нчы дәресләр

**1.** Текстны укы. Дару үләннәренең нинди файдасы бар?

### Шифалы табиблар

— Ромашка, Ромашка! Син кая чабасың?

— Гайнан бабайга салкын тигән, аның тамагы авырта. Мин бабайны дәвалыйм.

— Әрем, Әрем! Син кая йөгерәсең?

— Сара әбинең ашказаны авырта. Мин аны дәвалыйм.

— Кычыткан! Кычыткан! Син кая барасың?

— Искәндәр янына! Арт сабагын укытам! Бүген ул «ике»ле алган! Юньсез!

Вахит Монасыйповтан

**чабасың** — бежишь
**әрем** — полынь
**кычыткан** — крапива
**арт сабагын укытырга** — проучить
**юньсез** — бестолковый

**2.** Бу үләннәр нәрсә дәвалый?



**3.** Диалогны үзара сөйләшегез.

— Алсу, кайсы җирең авырта?
— Минем тамагым авырта.
— Минем дә тамагым авырта.
— Ә син дару эчтеңме?
— Юк, эчмәдем. Әбием: «Дару эчмә», — диде.
— Ә нәрсә эчтең?
— Ромашка белән чайкадым.

**4.** Рәсемнәргә кара һәм хайван, кош атамаларын үрнәк буенча яз.

Үрнәк:
Кошлар: тукран, ...
Хайваннар: аю, ...



**5.** Рәсемнәрдәге хайваннар һәм кошлар кайда яши? Үрнәк буенча яз.

Үрнәк: Чуртан суда яши.











**6.** Спроси у друга:

— нравится ли ему осенняя погода;
— слушал ли он прогноз погоды на завтра;
— нет ли на улице дождя;
— нравится ли ему природа родного края;
— какие лекарственные травы он знает.

**7.** Сообщи другу о том, что:

— вы в лесу собирали разные листья;
— в лесу было очень хорошо, интересно.

**8.** Убеди друга в том, что:

— в осеннем лесу очень красиво;
— надо собирать лекарственные травы.

## 37—39 нчы дәресләр

**1.** Кош исемнәрен дөрес итеп әйтергә өйрән. Тәрҗемәсен тап.

[қа°рлыйға́ч], [са°ндуға́ч], [күкә́], [чыйпчы́қ], [пә̆снә́к], [күгәрчә́н], [қа°рға́], [то̆рна́], [а°қ̄о́ш], [туқра́н], [қыйр қа°зы́], [қыйр үрдәгә́].

**2.** Рәсемнәргә кара һәм кош исемнәрен татарча әйт.



**3.** Нинди кошлар бездә кала, нинди кошлар бездән китәләр?

| Бездә кышлыйлар | Бездән китәләр |
|---|---|
| ... | ... |

Карлыгач, сандугач, күке, чыпчык, песнәк, күгәрчен, карга, торна, аккош, кыр казы, тукран, кыр үрдәге.

**4.** Спроси у друга:

— какие птицы зимуют у нас;
— какие птицы улетают в тёплые края.

**5.** Такмазаларны (прибаутки) укы. Ошаганын ятла.



Карга әйтә: «Кар, кар,
Җирдә чеби бар, бар.
Берсен генә алыр идем —
Саклаучысы бар, бар».

Тук, тук, тукран,
Тукылдатып утырам.
Агачтагы кортларның
Барсын чүпләп бетерәм.



**6.** Шигырьне укы, партадашың белән сәхнәләштер.

**Кошлар киткәндә**

— Сыерчыгым, нигә
китәсең?
Сагынырмын сине,
киткәчтен.
— Көз җитте бит инде,
мин туңам,
Килгән идем җәйге
костюмнан.

Бари Рәхмәт



**7.** Как скажешь о том, что:

— лето прошло;
— на улице стало холодно, дует холодный ветер?

**8.** Нокталар урынына җөмләләр яз. Иптәшең белән сөйләш.

— ... ?
— Әйе, сандугач җылы якка китә.
— ... ?
— Ә чыпчык җылы якка китми, бездә кала.

**9.** «Очты, очты...» уенын искә төшер!

**Очты, очты...**

Очты, очты — каргалар очты.
Очты, очты — чыпчыклар очты.
Очты, очты — курчаклар очты.
Очты, очты — уенчыклар очты.
Очты, очты — үрдәкләр очты.
Очты, очты — казлар очты.
Очты, очты — тазлар очты.
Очты, очты — тавыклар очты.



## 40—41 нче дәресләр

**1.** Кош исемнәрен алфавит тәртибендә яз.

Карга, күгәрчен, торна, акчарлак, сандугач, чыпчык, тургай, тукран, сыерчык, карлыгач, аккош, күке, песнәк.

**2.** Кошлар турында укы, иптәшләреңә сөйлә.

1. Песнәк — бик хәрәкәтчән, җитез кош. Ул бик тырыш. Тәүлегенә үз авырлыгы кадәр бөҗәк ашый. Җылы якларга китми, бездә кала. Кышын аңа җим бирәләр.

**хәрәкәтчән** — подвижная
**тәүлегенә** — в сутки
**җитез** — ловкая, юркая

2. Карлыгачлар чебен-черкиләр белән тукланалар. Алар сентябрьдә җылы якларга китәләр.

**3.** Бу кошлар нинди? Схемага карап әйт.

песнәк
карлыгач
?
хәрәкәтчән
җитез
матур
тырыш

**4.** Кошлар нәрсә белән туклана?

Песнәк ... белән туклана. Карлыгач ... белән туклана.

**5.** Әйтик, «Кошлар — безнең дусларыбыз» дигән кичә булачак. Син кошлар турында нәрсәләр беләсең? Дустыңа сөйләп кара.

**6.** Кошлар турында схема буенча диалог төзе.

Схема: вопрос — ответ — вопрос — ответ.

**7.** Текстны укы һәм әйт: Марат ничә кош исемен белә?

Маратларга кунак абый килде. Ул Маратка бер пакет күрсәтте һәм әйтте:

— Бу пакетта нәкъ егерме конфет бар. Әгәр егерме кош исеме әйтсәң (если скажешь), конфетларны сиңа бирәм.

— Чыпчык, карга, саескан, сандугач, песнәк, тургай, күгәрчен, каз, әтәч белән тавык һәм аларның ун чебиләре.

**8.** Спроси у друга:

— любит ли он птиц;
— каких птиц он знает;
— какие птицы остаются зимовать у нас;
— сделал ли он скворечник;
— делают ли у них в школе скворечники.



## 42—43 нче дәресләр

**1. Сүзләрне укы һәм исеңдә калдыр!**



**ашый** — кушает
**ашатам** — кормлю
**ашыйсы килә** — хочется есть
**эчә** — пьёт
**эчертәм** — пою
**эчәсе килә** — хочется пить

**2.** Нокталар урынына тиешле кушымчаларны куй.

1. Мин Акбай... ашатам. 2. Саша кошлар... ашата. 3. Алсу песи... сөт эчертә. 4. Әнисә песнәк... май ашата. 5. Песнәк... ашыйсы килә. 6. Мин энем... ботка ашатам. 7. Энем... ботка ашыйсы килә.

**3.** Диалогларны укы. Партадашың белән сөйләшеп кара.

1. — Оля, нәрсә ашыйсың килә?
— Мин бәлеш яратам.
— Минем өчпочмак ашыйсым килә.
— Әйдә пешерәбез.
2. — Энемнең ашыйсы килә.
— Әйдә ботка пешерәбез.
— Әйе, мин аңа ботка ашатам.

**4. Исеңә төшер!**

| **нәрсә?** | **нәрсәне?** | **нәрсәнең?** |
|---|---|---|
| песнәк | песнәкне | песнәкнең |
| ул | аны | аның |

**5.** Нокталар урынына тиешле кушымчалар куй, дәфтәреңә яз.

Песнәк кыш көне авыл... , шәһәр... яши. Балалар песнәк... ашаталар. Песнәк... дуслары күп.

**6.** 5 нче күнегүдәге җөмләләргә сораулар куй.

**7.** Хикәяне укы һәм уйла: Әнисә нинди кыз?

## Песнәк белән Әнисә

Кыш көне иде. Көннәр бик салкын. Беркөнне тәрәзәгә бер песнәк кунды. Ул тәрәзәне чукый башлады.

— Әни, нигә песнәк тәрәзәне чукый? — дип сорады Әнисә.

— Тышта нинди салкын! Аның ашыйсы килгән, — диде әнисе.

— Алайса мин аны ашатам, — диде Әнисә.



Ул тәрәзәне ачты һәм бер кисәк май куйды. Песнәк бик шатланды. Канатын какты, Әнисәгә рәхмәт әйтте.

Песнәк көн саен тәрәзәгә килеп куна иде. Ул Әнисәгә ияләште һәм ачык тәрәзәдән өйгә керә башлады.

Гасыйм Лотфидан

**кунды** — подсела
**чукый башлады** — начала клевать
**аның ашыйсы килгән** — она проголодалась
**канатын какты** — махнула крылышком
**ияләште** — привыкла

**8.** Бу сүзләрне дөрес укыйсыңмы? Аларны транскрипция билгеләре белән яз.

Беркөнне, песнәк, чукый, тышта, шатланды, кунды, канат.

**9.** Найди в тексте предложения о том, что:

— на улице холодно;
— синица проголодалась;
— Аниса накормила синицу.

**10.** Бу раслаулар дөресме?

— Көннәр салкын түгел иде.
— Песнәк ишек янына килде.
— Песнәк тәрәзәне чукый башлады.
— Песнәкнең ашыйсы килә.
— Песнәкнең өйгә керәсе килә.
— Әнисә песнәкне ашатмады.
— Песнәк майны ашап бетерде.
— Песнәк Әнисәдән курыкмады.
— Песнәк Әнисәгә ияләште.
— Песнәк өйгә керә башлады.

**11.** Хикәяне сәнгатьле укырга өйрән.

## 44—45 нче дәресләр

**1.** Җөмләләрне «Песнәк белән Әнисә» хикәясе эчтәлеге тәртибендә урнаштыр.

Беркөнне тәрәзәгә песнәк кунды. Кыш көне иде. Песнәк тәрәзәне чукый башлады. «Песнәкнең ашыйсы килгән», — диде әнисе. Песнәк Әнисәгә ияләште. Әнисә тәрәзәне ачты һәм бер кисәк май куйды. Песнәк Әнисәгә рәхмәт әйтте.

**2.** Нокталар урынына тиешле хәрефләрне яз.

1. Көн...әр бик салкын. 2. Берк...нн... тәр...зәгә п...сн...к кунды. 3. Т...р...з...н... ч...кый б...шл...-ды. 4. Песн...кнең ашый...ы килә иде. 5. Әнис... п...сн...к...ә май бирде. 6. Песн...к бик ш...тл...нды. 7. Пес...әк Әнис...г... и...ләште.

**3.** План пунктларын хикәя эчтәлеге тәртибендә урнаштыр (расположи пункты плана в последовательности содержания текста).

1. Әни белән кыз.
2. Көннәр бик салкын.
3. Песнәк Әнисәгә рәхмәт әйтә.
4. Әнисә песнәкне ашата.
5. Песнәк Әнисәгә ияләшә.

**4.** Иң яхшы хикәя сөйләүчегә конкурс! Бәя бирергә онытма!

**5.** Әгәр песнәк сөйләшә белсә, песнәк белән Әнисә арасында нинди сөйләшү булыр иде? Диалогны дәвам ит.

— Әнисә апа, исәнме!
— Исәнме, кошчыгым!
— Әнисә апа, миңа бик салкын!
— ... .

**6.** Фикерләрне дәвам ит.

Әнисә — яхшы кыз, чөнки ... .
Әнисә миңа ошый, чөнки ... .
Әнисә кошларны ярата, шуңа күрә ... .

**7.** Әгәр Әнисә яхшы күңелле кыз булмаса, кошларны яратмаса (если бы не любила птиц), хикәя ничек үзгәрер иде? Яңа хикәя язып кара.

**8.** Спроси у друга:

— помогает ли он птицам;
— сделал ли он кормушку;
— кормит ли он птиц.

**9.** Рәсемнәр урынына — күплек сандагы исемнәр, нокталар урынына кушымчалар куй, җөмләләрне дәфтәреңә яз.

Без  ... бик яратабыз. Без аларга  куябыз.  ...  сала... .

## 46 нчы дәрес

**1. Исеңә төшер!**



**Ул бар-а.** — Он идёт.
**Ул бар-мый.** — Он не идёт.
**Ул бар-ды.** — Он ходил.
**Ул бар-ма-ды.** — Он не ходил.

2. Үрнәк буенча таблицаны тутыр.

| | Хәзерге заман хикәя фигыль | | Үткән заман хикәя фигыль | |
|---|---|---|---|---|
| | барлык | юклык | барлык | юклык |
| бар<br>кит<br>кайт<br>аша | бар-а | бар-мый | бар-ды | бар-ма-ды |

3. Нокталар урынына кирәкле кушымчаларны куеп укы.

Мин бакча... бар... . — Я иду в сад.
Мин бакча... кайт... . — Я пришёл из сада.
Мин бакча... эшлә... . — Я работал в саду.
Мин өй... кайт... . — Я пришёл домой.
Мин өй... эшлә... . — Я работал дома.
Мин өй... чык... . — Я вышел из дома.
Мин бакча... бар... . — Я не пойду в сад.
Мин бакча... кайт... . — Я не вернусь из сада.
Мин бакча... эшлә... . — Я не работал в саду.
Мин өй... кайт... . — Я не приду домой.
Мин өй... эшлә... . — Я не работал дома.
Мин өй... чык... . — Я не выходил из дома.

**4.** Үрнәк буенча тәрҗемә ит.

1. Мин бара алам. — Я могу идти.
   Мин бара алмыйм. — Я не могу идти.
2. Кошчык оча.
   Кошчык оча алмый.
3. Кошчык ашый ала.
   Кошчык ашый алмый.
4. Кошчык сайрый ала.
   Кошчык сайрый алмый.

**5.** Восстанови диалог, поговори с соседом по парте.

— ... ?
— Мин бакчага бардым.
— ... ?
— Әйе, әни эштән кайтты.
— Ул бакчага барамы?
— ... .

**6.** Составь диалог по образцу упр. 5.

## 47—48 нче дәресләр

**1.** **Исеңә төшер!**






**2.** Җөмләләрне укы, сораулар куй.

1. Кар өстендә бер кош ята.
2. Үләннәр кар астында калды.
3. Өстәл янында урындык бар.

**3.** Рәсемгә кара һәм уйла: нокталар урынына нинди сүзләр куярсың? Дәфтәреңә тәрҗемәләре белән яз.



**4.** Бу сүзләрне исеңдә калдыр! Тәрҗемәсен сүзлеккә яз. Алар сиңа хикәяне аңларга ярдәм итәр.

| | | |
|---|---|---|
| өшегән — ... | кызганыч — ... | ярма — ... |
| авырта — ... | кинәт — ... | борын — ... |
| туңган — ... | эремчек — ... | җим — ... |

**5.** Хикәяне укы.

**Чирик**



Бик салкын кыш көне иде. Әнием белән бакчадан кайтабыз. Кар өстендә бер чыпчыкны күрдек. Кошчык оча алмый, канаты авырта. Ул туңган. Тәпиләре кып-кызыл. Кошчыкны бик кызгандык. Без аны өйгә алып кайттык. Алдына сөт, эремчек, ярма куйдык. Ләкин ул ашамады. Башын түбән иде,

күзләрен йомды. Кошчык икенче көнне генә күзләрен ачты. Миңа бик озак карап торды.

Мин чыпчыкны ашый белми, дип уйладым. Өстәлдәге тарыны борыным белән чукып күрсәттем. Кинәт кошчык: «Чирик... чирик», — дип куйды. Шулай итеп, аның исеме Чирик булды.

**бакча** — здесь: детский сад
**уйладым** — подумал
**тары** — просо
**чукып күрсәттем** — показал, как клевать
**ашый белми, дип уйладым** — подумал, что не умеет есть
**шулай итеп** — итак

**6.** Рәсемгә кара һәм әйт: кыз кошка нинди ризыклар бирде?




**7.** Бу сүзләрне дөрес укыдыңмы? Транскрипция белән яз.

Салкын, кайтабыз, өшегән, озак, кошчык, кызгандым, эремчек, ярма, йомды, ачты.

**8.** Хикәяне план буенча өлешләргә бүлеп укы.

1. Без бакчадан кайтабыз.
2. Чыпчыкны өйгә алып кайттык.
3. Мин чыпчыкны ашый белми, дип уйладым.

**9.** Найди в тексте предложения о том, что:

— птичке очень холодно;
— птичка даже есть не хочет;
— птичка только на другой день открыла глаза.

**10.** Бу җөмләләр хикәя эчтәлегенә туры киләме?

1. Кошларга кыш көне салкын. 2. Кошларга бик җылы. 3. Кошлар кыш көне туңалар. 4. Кешеләр кошларга җимлек ясыйлар. 5. Кешеләр кошларны кызганмыйлар. 6. Кечкенә кызчык кошчыкны бик кызгана. 7. Кошчык башта ук кыздан курыкмады. 8. Кызчык кошчыкны ашатырга теләмәде. 9. Кошчык икенче көнне генә күзләрен ачты.

**11.** Бу сүзләрне тәрҗемә ит. Алар белән җөмләләр төзе.

| | |
|---|---|
| спереди — ... | над — ... |
| сзади — ... | под — ... |
| напротив — ... | около — ... |

**12.** Җөмләләрне киңәйтеп яз.

1. Без күрдек. 2. Алдына куйдык. 3. Мин уйладым.

**13.** Җөмләләрне дәвам ит.

1. Без әнием белән кар өстендә ... . 2. Кошчыкның канаты ... . 3. Без кошчыкны бик ... . 4. Аны өйгә ... . 5. Кошчыкның алдына ... . 6. Кошчык икенче көнне генә ... .

**14.** Сорауларга җавап бир.

1. Көн нинди иде?
2. Әни белән кыз кар өстендә нәрсә күрделәр?
3. Кош нинди иде?
4. Кошчыкны кая алып кайттылар?
5. Кошчык алдына нәрсә куйдылар?
6. Кыз кошчыкка ни өчен Чирик исемен кушты?

**15.** Хикәянең эчтәлеген сораулар буенча сөйләргә өйрән.

## 49—50 нче дәресләр

**1.** **Исеңдә калдыр!**

Если хочешь сказать, что он (она) любит что-либо делать, то говоришь так:

**Ул уйнарга ярата.** — Он (она) любит играть.

**Ул су коенырга ярата.** — Он (она) любит купаться.

**2.** Как скажешь о том, что:

— птица любит купаться;
— девочка любит играть;
— ученик любит читать?

**3.** Тәрҗемә ит.

Ү р н ә к: эшли башлады — начал работать.

| | |
|---|---|
| чукый башлады | оча башлады |
| ашый башлады | килә башлады |
| уйный башлады | чыга башлады |

**4.** Бу сүзләрне онытма! Алар сиңа Чирик турындагы хикәяне аңларга ярдәм итәр.

| | |
|---|---|
| **сәламәт** — здоровый | **шаярырга** — баловаться |
| **җилкә** — плечо | **юкка чыкты** — исчез |
| **шартлады** — лопнул | **курыкты** — испугался |

**5.** Хикәяне укы. Чирик ничек үзгәрде?

**Чирик**
(дәвамы)

Чирик ашарга да өйрәнде, оча да башлады. Җилкәмә куна да: «Чик-чирик, чик-чирик!» — ди.

Хәзер Чирик сәламәт. Ул су коенырга, шар шартлатырга ярата.

Яңа елда Чирик шарлар янына килде дә чукый башлады. Кинәт бер шар шартлады. Әй курыкты соң Чирик! Ләкин ул барыбер шарлар белән шаярды, уйнады.

**шар шартлады** — шар лопнул

**6.** Рәсемгә туры килгән җөмләне хикәядән табып укы.



**7.** Бу раслаулар дөресме?

— Чирик ашамый.
— Чирик ашарга өйрәнде.
— Чирик очарга өйрәнде.
— Чирик тәрәзәдән чыга да кире кайтмый.
— Чирик шарлар шартлата.
— Чирик курыкмады.
— Чирик шарлар белән шаярды.
— Шар шартламады.
— Шар шартлады.

**8.** Җөмләләрне дәвам ит.

1. Кошчык ашарга да өйрәнде, оча ... . 2. Хәзер инде ул ... . 3. Чирик шарлар янына килде дә ... . 4. Шар ... , ә Чирик ... .

**9.** Җөмләләрне хикәя эчтәлеге тәртибендә урнаштыр.

Яңа елда чыршыда шарлар күп иде. Чирик шарларны чукый башлады. Чирик шарлар белән уйнарга яратты. Кошчык ашарга да өйрәнде, оча да башлады. Чирик хәзер сәламәт. Чирик су коеныргa, шар шартлатырга ярата. Шар кинәт шартлады, ә Чирик курыкты.

**10.** «Иң яхшы хикәя сөйләүче» конкурсына әзерлән. «Чирик» хикәясен иптәшеңә сөйләп кара.

**11.** Скажи другу о том, что:

— ты здоров;
— ты любишь купаться, играть в футбол;
— любишь играть на улице.

**12.** Спроси у друга:

— любит ли он купаться, играть в футбол, играть с шарами.

**13.** Сообщи о том, что ты начал:

— читать интересную книгу, ходить в волейбольный кружок, ходить в бассейн.

## 51—52 нче дәресләр

**1. Исеңә төшер!**

При выражении принадлежности предмета кому-либо или чему-либо к основе слова присоединяются следующие аффиксы:

| | | |
|---|---|---|
| 1 лицо | **-ым/-ем,** | **кош-ым** — моя птица |
| | | **өстәл-ем** — мой стол |
| | **-м** | **апа-м** — моя сестра |
| | | **сөлге-м** — моё полотенце |
| 2 лицо | **-ың/-ең,** | **кош-ың** — твоя птица |
| | | **өстәл-ең** — твой стол |
| | **-ң** | **апа-ң** — твоя сестра |
| | | **сөлге-ң** — твоё полотенце |
| 3 лицо | **-ы/-е,** | **кош-ы** — его (её) птица |
| | | **өстәл-е** — его (её) стол |
| | **-сы/-се** | **апа-сы** — его (её) сестра |
| | | **сөлге-се** — его (её) полотенце |

Но в словах, оканчивающихся на **к**, **п**, при добавлении аффиксов принадлежности эти звуки в конце слова чередуются со звонкими парами:
**к — г, п — б:**

**күлмәк** — күлмәге, **китап** — китабы.

| Лицо | | Множественное число |
|---|---|---|
| | Аффиксы | Примеры |
| 1 | **-ыбыз/**<br>**-ебез,**<br>**-быз/**<br>**-без** | **кош-ыбыз** — наша птица<br>**өстәл-ебез** — наш стол<br>**апа-быз** — наша сестра<br>**сөлге-без** — наше полотенце |
| 2 | **-ыгыз/**<br>**-егез,**<br>**-гыз/**<br>**-гез** | **кош-ыгыз** — ваша птица<br>**өстәл-егез** — ваш стол<br>**апа-гыз** — ваша сестра<br>**сөлге-гез** — ваше полотенце |
| 3 | **-лары/**<br>**-ләре,**<br><br><br>**-нары/**<br>**-нәре** | **кош-лары** — их птица<br>**өстәл-ләре** — их стол<br>**апа-лары** — их сестра<br>**сөлге-ләре** — их полотенце<br>**урман-нары** — их лес<br>**көн-нәре** — их дни |

**2.** Кушымчалар куй, җөмләләр төзе.

Минем — чәч, кул, аяк(г), күз, колак(г), сөлге — ? — -ым, -ем, -м

Синең — туп(б), сумка, күлмәк(г), курчак(г), шар — ? — -ың, -ең, -ң

**3.** Найди существительное с аффиксами принадлежности (тартымлы исемнәр).

1. Бар минем
Кошчыгым —
Кечкенә чыпчыгым.

Әнәс Кари

2. Китап — киңәшчең синең,
Дустың, ярдәмчең синең.

Хәсән Шабанов

**4.** Диалогларга төшеп калган репликаларны өстә.

а) — ... ?
— Әйе, минем өйдә аквариумым бар.
— ... ?
— Төрле балыкларым бар.
— Миңа бер балык бир әле.
— ... .

ә) — ... ?
— Әйе, мин бу китапны укыдым.
— ... .
— Миңа ул бик ошады.
— Ул нәрсә турында?
— ... .

**5.** Прочитай слово **курчакларымны**. Какие аффиксы присоединены к основе?

**6. Исеңдә калдыр!**



Аффиксы присоединяются к основе существительного в следующем порядке: сначала — аффикс числа, затем аффикс принадлежности и падежный аффикс:

күз + **ләр** + **ем** + **нең,**
курчак + **лар** + **ым** + **ны.**

**7.** Сүзләрне укы. Кушымчаларны әйт. Аларны үрнәктәгечә аерып яз.

Үрнәк: курчагымны — курча(к)г-ым-ны;
кулына — кул-ы-на.

Күлмәк, кошчыгым, чыпчыкларым, җилкәмә, җилкәмне, күземне, күземә, әтиемне, әниемә.

**8.** Диалогны дәвам ит. Иптәшең белән сөйләш.

— Коля, синең попугаең бармы?
— Бар.
— Син попугайга нәрсәләр ашатасың?
— ... .

**9.** 8 нче күнегүдәге диалогка охшаш диалог төзе.

## 53 нче дәрес

**1. Исеңдә калдыр!**

**кайвакыт** — иногда
**бервакыт** — однаждды
**инде** — уже, уж, же

**2.** Җөмләләрне тәрҗемә ит.

1. Я учусь в четвёртом классе.
2. Я уже хорошо говорю по-татарски.
3. Иногда я плохо готовлюсь к урокам.
4. Однажды в лесу он увидел ёжика.

**3.** Дөрес тәрҗемәне тап.

1) урамга чыктым / урамда уйныйм / урамнан кердем — ? — пришёл с улицы / вышел на улицу / играю на улице

2) очып керә / очып чыга — ? — вылетает / залетает

3) кулымны күтәрдем / кулымны төшердем — ? — опустил руку / поднял руку

4) һавага менә / җиргә төшә — ? — спускается на землю / поднимается в небо

5) алып кайтты / алып китте — ? — унёс / принёс

**4.** Җөмләләрне укы. Калын хәреф белән бирелгән сүзләрнең кушымчаларын билгелә.

1. Шарларны **Алсуның кулына** бәйләдем.
2. **Җилкәмә** Чирик утырды.
3. Мин **кулымны** күтәрдем.
4. Шарлар **курчагымны һавага** алып менеп киттеләр.

**5.** Сүзләрнең тәрҗемәсен тап. Дөрес укырга өйрән.

Яши [йәши́], онытмый [ŏнŏ́тмы̆й], аллы-гөлле [а°л̄ы́гөл̄ө], эскәмия [э̆скәмийә́], янында [йа°нŭында́], коткарды [қŏтқарды́].

**6.** Җөмләләргә сораулар куй. Кем күпме сорау уйлап таба ала?

1. Кош безгә очып керә.
2. Әтием миңа матур шарлар алып кайтты.
3. Шарларны курчагымның кулына бәйләдем.
4. Җилкәмә кош килеп кунды.
5. Мин кулымны күтәрдем.
6. Шарлар һавага очтылар.

**7.** Җөмләләрне тиз укырга өйрән.

1. Мин бәйләдем.
   Мин шарларны бәйләдем.
   Мин шарларны кулга бәйләдем.
   Мин шарларны курчакның кулына бәйләдем.
   Мин шарларны курчагым Алсу кулына бәйләдем.

2. Мин утырдым.
Мин эскәмиягә утырдым.
Мин урамда эскәмиягә утырдым.

3. Мин чыктым.
Мин урамга чыктым.
Мин урамга чыктым һәм эскәмиягә утырдым.

**8.** Җөмләләрне киңәйтеп яз.



1. Чирик ярата.
2. Чирик шартлатты.

## 54—55 нче дәресләр

**1.** Хикәяне укы.

### Чирик
(дәвамы)



Менә җәй җитте. Чирик инде урамда яши, ләкин ул мине онытмый. Кайвакыт безгә дә очып керә.

Бервакыт әтием шарлар алып кайтты. Шарларны курчагым Алсуның кулына бәйләдем дә урамга чыктым, эскәмиягә утырдым. Җилкәмә Чирик килеп кунды. Мин, «көш-ш-ш!» дип, кулымны күтәрдем, ә шарлар курчагымны һавага алып менеп киттеләр.

— Курчак очты! Алсу очты! — дип кычкырдым, елый башладым. Миңа берәү дә ярдәм итә алмады.

Кинәт шарлар шартлады, һәм Алсу җиргә төшә башлады. Мин һавага карадым һәм шаккаттым: Алсу янында Чирик очып йөри иде. Менә ул бер шарны шартлатты, икенче шарны, тагын, тагын... Чирик Алсуны коткарды.

Җәвад Тәрҗеманов

**шаккаттым** — удивилась
**коткарды** — спас
**шарны шартлатты** — здесь: птичка клюнула, и шар лопнул.

**2.** Бу сүзләрне дөрес укыдыңмы?

[қа́°йwақы̆т], [бә́рwақы̆т], [урамға́ чы̆қты́м], [қурчағы̆мны́], [қы̆чқы̆рды́м].

**3.** Бу җөмләләргә ничә сорау бирә аласың?

1. Бервакыт әтием шарлар алып кайтты. 2. Шарларны курчагым Алсуның кулына бәйләдем дә урамга чыктым.

**4.** Җөмләләрне текст эчтәлеге тәртибендә урнаштыр.

Кайвакыт Чирик безгә дә очып керә. Ул мине онытмый. Чирик инде урамда яши. Шарларны курчагым Алсуның кулына бәйләдем дә урамга чыктым, эскәмиягә утырдым. Мин, «көш-ш-ш!» дип, кулымны күтәрдем, ә шарлар курчагымны һавага алып менеп киттеләр. Җилкәмә Чирик кунды.

**5.** Җөмләләрне дәвам ит.

1. Чирик инде урамда яши, чөнки … .
2. Чирик безгә очып керә, чөнки … .
3. Шарлар һавага очтылар, чөнки … .
4. Шарлар һавада шартладылар, чөнки … .
5. Чирик миңа ияләште, чөнки … .
6. Мин кулымны күтәрдем, чөнки … .
7. Чирик шарларны шартлатты, чөнки … .

**6.** Рәсемнәр урынына — сүзләр, нокталар урынына кушымчалар куй. Текстны дустыңа сөйләп кара.

Мин  …  … кулына бәйләдем дә урам… чыктым, … утырдым. Җилкәмә  килеп кунды. Мин кул… күтәрдем, ә   … һавага алып менеп киттеләр. Мин һава… карадым һәм шаккаттым:  янында  очып йөри иде. Ул бер  … шартлатты.  Алсу… коткарды.

**7.** Сорауларга җавап бир.

1. Чирик җәй көне кайда яши башлады?
2. Чирик кечкенә кызны ни өчен онытмый?
3. Әтисе кызга нәрсә алып кайтты?
4. Кыз кая чыкты?
5. Ул шарларны нәрсәгә бәйләде?
6. Шарлар нигә очып киттеләр?
7. Кыз нигә шаккатты?

**8.** Әгәр хикәя III зат исеменнән сөйләнсә (кызның исеме — Ләйсән), кайсы җөмләләр үзгәрер иде? Хикәядән фигыльләрне тап, таблицага яз.

| I зат — **мин** | III зат — **ул** |
|---|---|
| бәйләдем<br>... | бәйләде<br>... |

**9.** Иң матур хикәя сөйләүчегә конкурс! Конкурс төркемнәр арасында үткәрелә. «Чирик» хикәясен бер-берегезгә сөйләгез. Җиңүчеләрне билгеләгез.

**10.** Как скажешь о том, что ты можешь:

— хорошо учиться;
— красиво рассказывать стихотворение;
— решить задачу;
— быстро бегать?

**11.** Скажи братику, что зимой птицам холодно. Убеди его в том, что надо им делать кормушку, надо их кормить.



## 56—57 нче дәресләр

### Проверь себя!

**1.** Нокталар урынына тиешле хәрефләрне яз.

Ак...ош, к...гәрчен, үрд...к, та...ык, т...р...зә, шатл...на, хәрәк...тч...н.

**2.** Дөрес тәрҗемәне тап.

Ловкий —
1) файдалы; 2) җитез; 3) шат.

Голубь —
1) күгәрчен; 2) карлыгач; 3) тукран.

**3.** Как ты спросишь у друга:

— любит ли он птиц;
— когда улетают птицы;
— какие птицы остаются у нас, а какие улетают в тёплые края;
— кормит ли он зимой птиц;
— чем он кормит птиц зимой?

**4.** Сүзләрнең антоним парларын тап.

| | | |
|---|---|---|
| җылы | | тар |
| тырыш | | батыр |
| киң | ? | әкрен |
| куркак | | ялкау |
| җитез | | салкын |
| матур | | ямьсез |

**5.** Вспомни рассказ «Песнәк белән Әнисә». Что ты можешь сказать о девочке Анисе? Какая она?

**6.** Син нинди кошларны беләсең, алар турында нәрсәләр сөйли аласың?

**7.** Җөмләләрне дәвам ит.

1. Песнәк — файдалы кош, чөнки ... .
2. Көз көне салкын яңгыр ява, шуңа күрә ... .
3. Мин көзне яратам, ләкин ... .

**8.** Нокталар урынына кушымчалар яз.

Кышын бездә яшиләр
Песнәк... һәм чыпчык... ,
Күгәрчен... , чәүкә... ,
Тагын башка кошчыклар.

Гасыйм Лотфи

**9.** Тәрҗемә ит.

1. Я жалею птиц, поэтому их кормлю. 2. Я насыпала корм птицам. 3. Мы сделали кормушки для птиц. 4. Я начал хорошо решать задачи. 5. Я люблю купаться, поэтому хожу в бассейн. 6. Я люблю читать, поэтому часто хожу в библиотеку.

**10.** Диалогны өйрән, дустың белән сөйләш.

— Син кошларны яратасыңмы?
— Әлбәттә.
— Ә быел җимлек ясадыңмы?
— Әйе.
— Кая элдең?
— Бакчага.

**11.** Кроссвордны чиш.






**1—2.** Йорт кошлары.

**3.** Җылы якка китүче кош.

**4.** Сары түшле кош (птица с жёлтой грудкой).

# ХАЙВАННАР ДӨНЬЯСЫНДА

## 58 нче дәрес

**1.** Рәсемнәргә кара һәм әйт: бу хайваннарның кайсысы — авылда, кайсысы урманда яши?



**2.** Сүзләрне тәрҗемә ит, дөрес әйтергә өйрән.

Соры, ак, кара, озын колаклы, озын койрыклы, хәйләкәр, усал, ит бирә, сөт бирә, йон бирә, тиз йөгерә, зур.

**3.** Беренче рәсемдәге хайваннар турында син нәрсәләр сөйли аласың?

**4.** Табышмакларны укы. Җавапларны рәсемгә карап әйт.



1. Сорыдыр төсе,
Үткендер теше,
Урманда йөри,
Сарыклар эзли.

2. Нечкә билле,
Көлтә койрыклы.



3. Бер йомгакка мең энә,
Сиңа тими, син тимә.

4. Җәен соры, кышын ак,
Аңа шулай яхшырак.





**5.** Табышмаклардагы тасвирлауларны (описания) кулланып, рәсемдәге хайваннар турында сөйлә.

**6.** Диалогларга төшеп калган җөмләләрне өстә. Дустың белән сөйләшеп кара.

1. — Оля, син бүре күрдеңме?
   — ... .
   — ... ?
   — Зоопаркта. ... ?
   — Ә мин мультфильмда.

2. — ... .
   — Әйе, мин куян күрдем.
   — ... ?
   — Урманда.
   — ... ?
   — Җәй көне.
   — Куян нинди төстә иде?
   — ... .

**7.** Бергәләп уйнагыз.

— Дуслар, кая барасыз?
— Кара урманга барабыз.
— Кара урманда нишлисез?
— Кура җиләге җыябыз.
— Җиләк белән нишлисез?
— Җиләктән как коябыз.
— Бүре килсә, нишлисез?
— Урман буйлап чабабыз.

Балалар фольклорыннан

**8.** Үзеңә ошаган табышмакларны ятла.

## 59 нчы дәрес

**1.** Тиен турында сөйләргә өйрән.



**Тиен**

Урманда бар зур койрыклы
Житез тиен.
Агач башларында яши
Кышын-җәен.
Агачлардан агачларга
Сикереп үтә,
Чикләвекләр ашап, шунда
Гомер итә.

Әнәс Кари

**2.** Бу сүзләрне дөрес укыдыңмы? Транскрипция билгеләре белән яз.

Койрыклы, кышын, агачлардан, чикләвекле, гомер.

**3.** Шигырьдән **кая? кайдан? кайда?** сорауларына җавап булып килгән исемнәрне тап.

**4.** Җөмләләрне төгәллә.

1. Тиен җитез, ... . 2. Тиен кышын, җәен ... . 3. Тиен агачтан агачка ... . 4. Тиен чикләвек ... .

**5.** 4 нче күнегүдәге җөмләләргә сораулар куй.

**6.** Шигырьне яттан сөйләргә өйрән.

## 60—61 нче дәресләр

**1. Исеңә төшер!**

**Билгесез үткән заман хикәя фигыль**
**Прошедшее неопределённое время глагола**

Если говоришь о событиях, которых сам не видел, то употребляешь глагол в такой форме:

**Ул кайт-кан.** — Он вернулся (оказывается).
**Ул әйт-кән.** — Он сказал (оказывается).
**Ул бар-ган.** — Он ходил (оказывается).
**Ул кер-гән.** — Он заходил (оказывается).

**2.** Тәрҗемә ит.

1. Он к нам, оказывается, приходил. 2. Она, оказывается, вернулась. 3. Она, оказывается, оставила лекарственные травы. 4. Он, оказывается, маме сказал.

**3. Бу сүзләрне онытма!**

**ярыш** — соревнование
**ярыша** — соревнуется
**ярышта катнаша** — участвует в соревновании
**ярышырга тели** — хочет соревноваться

**4.** Сүзләрне дөрес укырга өйрән, тәрҗемәсен тап.

[таᵒшбаҡа́], [ҡуйа́н], [тə̆ләгән̄ә́р], [баᵒшлаға н̄а́р], [йŏҡло́й], [уйана́], [үкә̆ндә́], [фаᵒйда́].

**5.** Хикәяне укы. Куян нигә үкенде?

### Ташбака белән Куян



Ташбака белән Куян ярышырга теләгәннәр. Алар бер тауга таба йөгерә башлаганнар. Куян, мин тиз йөгерәм, дип уйлый. Ул юлда йоклый.

Куян бервакыт уяна. Күрә: Ташбака тауга барып җиткән. Куян үкенде дә, хурланды да, әмма ни файда?!

Габдулла Тукайдан



**үкенде** — раскаялся
**дип уйлый** — думает, что ...
**хурланды** — стыдился
**тауга таба** — в сторону горы

**6.** Дөрес тәрҗемәне тап.

Йоклый —
1) заснул; 2) спит; 3) спят.

Бервакыт —
1) вчера; 2) однажды; 3) иногда.

Уяна —
1) проснулся; 2) просыпается; 3) проснулись.

**7.** Ике раслауның кайсысы дөрес?

1. Ташбака белән Куян бер елгага таба йөгерә башлаганнар.
Ташбака белән Куян бер тауга таба йөгерә башлаганнар.
2. Ташбака, мин тиз йөгерәм, дип уйлый.
Куян, мин тиз йөгерәм, дип уйлый.
3. Ташбака юлда йоклый.
Куян юлда йоклый.
4. Куян тауга барып җиткән.
Ташбака тауга барып җиткән.
5. Куян үкенде дә, хурланды да, әмма үкенүдән ни файда?!
Ташбака үкенде, хурланды, ләкин үкенүдән ни файда?!

**8.** Хикәядәге җөмләләргә сораулар куй. Кем күбрәк сораулар уйлап таба?

**9.** Как скажешь о том, что ты:

— участвуешь в соревнованиях;
— на соревновании пришёл первым;
— победил;
— не победил;
— раскаялся?

**10.** Бу мәкальне (пословицу) ничек аңлыйсың?

Эш уткәч, үкенүдән файда юк.

**11.** 8 нче күнегүне язмача эшлә.

**12.** «Ташбака белән Куян» хикәясенең эчтәлеген дустыңа сөйлә.

## 62—63 нче дәресләр

**1. Исеңдә калдыр!**

Когда сравниваем признаки предметов, говорим так:

**зур-рак** — больше, **матур-рак** — красивее,
**яшел-рәк** — зеленее, **кечкенә-рәк** — меньше.

А когда выражаем превосходство какого-либо качества, то говорим:

**бик зур** — очень большой,
**бик матур** — очень красивый,
**ап-ак** — белый-пребелый,
**иң зур** — самый большой,
**иң матур** — самый красивый,
**ямь-яшел** — зелёный-презелёный,
**зәп-зәңгәр** — синий-пресиний,
**сап-сары** — жёлтый-прежёлтый,
**кып-кызыл** — красный-прекрасный.

**2.** Прочитай предложения. Найди прилагательные и определи, как выражены признаки предметов.

1. Бу алма кызыл. Өстәлдәге алма кызылрак. Ә агачтагы алма кып-кызыл. 2. Бу чәчәкләр зәңгәр, ә бу чәчәк зәп-зәңгәр. 3. Бу күлмәк чиста, ап-ак. 4. Синең бантигың бик матур. 5. Миңа иң зур алманы бир әле. 6. Бу алма зуррак, матуррак.

**3.** Бер-берегезгә карап, комплиментлар әйтегез.

**4.** Бу җөмләләр кайсы рәсемгә туры килә?

1. Бу — иң зур помидор. 2. Бу помидор кечкенә. 3. Бу — зур помидор. 4. Бу помидор зуррак. 5. Бу помидор бик зур.



**5. Бу сүзләрне исеңдә калдыр!** Алар сиңа әкиятне аңларга ярдәм итәр.



**керпе** — ёж
**энә** — игла
**зур үскән** — вырос
**җәнлекләр** — звери
**кия** — надевает
**шундый** — такой
**ышанмаган** — не поверил

**6.** Үрнәк буенча дәвам ит.

| **нишли?** | **нишләгән?** | **нишләми?** | **нишләмәгән?** |
|---|---|---|---|
| уйлый<br>күрә<br>кия<br>исни<br>җырлый<br>сөйли<br>бии<br>китә | уйла-ган<br>күр-гән | уйла-мый<br>күр-ми | уйла-ма-ган<br>күр-мә-гән |

## 64—65 нче дәресләр

**1. Исеңә төшер!**

| кая? | кайда? | кайдан? |
|---|---|---|
| **чыршы янына**<br>к ёлке | **чыршы янында**<br>у (около) ёлки | **чыршы яныннан**<br>от ёлки |

**2.** Дөрес укы.

[кӗ̆рпә́ ба°ласы́], [бә́рwақы̆т], [чы̆ршы́], [йәмйәшә́л], [йа°ңа́ йыл бәйрәмә́], [а°ны́ң йа°ны̆нда́], [җы̆рлады̆ла́р], [бийэдэлө́р], [җәнлэклө́р].

**3.** Дөрес тәрҗемәне тап.

Бервакыт —
1) иногда; 2) однажды; 3) когда.

Тун —
1) пальто; 2) шуба; 3) одежда.

Уйлаган —
1) сказал; 2) подумал; 3) говорил.

**4.** Әкиятне укы. Керпе баласына нәрсә ошаган? Ни өчен?



### Яшел энәле керпе

Бервакыт Керпе баласы урманда чыршы күргән. Бик озак чыршыга карап торган, энәләрен иснәгән.

— Нинди зур керпе, нинди матур керпе! — дигән. — Менә кызык, энәләре ямь-яшел! Зур ускәч, мин дә шундый тун киям, — дип уйлаган.

Менә ул Яңа ел бәйрәменә киткән. Анда бик матур чыршы күргән.

— Күрдеңме? — дигән ул Аю баласына. — Нинди матур керпе! Барлык җәнлекләр дә зур керпе янында җырладылар, шигырь сөйләделәр, биеделәр.

Аю баласы көлгән:

— Ул бит керпе түгел, чыршы! — дигән.

Керпе баласы һаман ышанмаган.

— Чыршы булса да, ул — зур керпе! — дигән.

**энәләрен иснәгән** — понюхал иголки
**һаман** — всё ещё
**ышанмаган** — не поверил
**булса да** — если даже
**сокланган** — восхитился

**5.** Әкият эчтәлегенә туры килә торган җөмләләрне тап, дәфтәреңә яз.

1. Керпе баласы урманда чыршы күргән. 2. Керпе баласы ямь-яшел чыршыны бик яраткан. 3. Керпе баласы ямь-яшел энәле чыршыга карап сокланган. 4. Керпе баласы чыршыны зур керпе, дип уйлаган. 5. Ул Яңа ел бәйрәмендә тагын чыршыны күргән һәм шатланган. 6. Аю баласы Керпе баласыннан көлгән.

**6.** Әкият текстыннан фигыльләрне тап һәм үрнәк буенча үзгәрт.

Үрнәк: күргән — күрде.

**7.** Әкиятне сәнгатьле укырга өйрән.

## 66—67 нче дәресләр

**1.** «Яшел энәле керпе» әкиятен исеңә төшер. Ике раслауның кайсысы дөрес?

1. Керпе баласы урманда нарат күргән.
   Керпе баласы урманда чыршы күргән.

2. Керпе баласына чыршы ошаган.
   Керпе баласы чыршыны яратмаган.

3. Керпе баласы чыршыны зур керпе, дип уйлаган.
   Керпе баласы чыршыны зур аю, дип уйлаган.

4. Җәнлекләр чыршы янында җырлар җырлыйлар, шигырь сөйлиләр, бииләр.
   Җәнлекләр чыршы янында шигырь сөйлиләр, китап укыйлар.

**2.** «Яшел энәле керпе» әкиятеннән үзеңә иң ошаган җөмләләрне табып укы. Бу җөмләләр сиңа ни өчен ошады?

**3.** Җөмләләрне киңәйтеп яз.

1. Керпе баласы күргән. 2. Тун киям. 3. Җәнлекләр биеделәр.

**4.** Түбәндәге җөмләләргә кем күбрәк сораулар куя ала?

1. Бервакыт Керпе баласы урманда чыршы күргән. 2. Бөтен җәнлекләр дә чыршы янында җырлар җырладылар, шигырь сөйләделәр, биеделәр. 3. Керпе баласы ямь-яшел чыршыны бик яраткан.

**5.** Сорауларга җавап бир. Сораулар буенча әкиятнең эчтәлеген дустыңа сөйләп кара.

1. Керпе баласы урманда нәрсә күргән?
2. Ул ни өчен чыршыны зур керпе дип уйлаган?
3. Ни өчен аңа чыршы бик ошаган?
4. Керпе баласы чыршыны тагын кайчан күргән?
5. Җәнлекләр чыршы янында нинди уеннар уйнаганнар?
6. Ни өчен Керпе баласы: «Чыршы булса да, ул — зур керпе!» — дигән?

**6.** Диалогка төшеп калган җөмләләрне куй.

— Исәнме, аю!
— ... .
— Мин урманда булдым, анда зур керпе күрдем.
— ... .
— Ул бик зур, ямь-яшел, энәләре хуш исле.
— ... .
— Чыршы булса да, ул — зур керпе.

**7.** Әкиятне сөйләргә өйрән.



## 68—69 нчы дәресләр

**1.** Текстны укы. Ә синең керпе күргәнең бармы?

Безнең урманнарда, бакчаларда керпе еш очрый. Зур керпенең энәсе 16 меңгә якын була. Энәнең озынлыгы 2—4 сантиметр, юанлыгы 1 миллиметр. Керпенең авырлыгы 1 килограммга, буе 30 сантиметрга җитәргә мөмкин.

Көз көне керпе тыныч урынга коры яфрак, үлән ташый. Ул кыш буе йоклый. Керпе бөҗәкләр, тычкан, гөмбә, җиләк, үлән ашый.



**2.** Дөрес укыдыңмы?

[кә̆рпә́], [ŏзŏнлы́к], [йуанлы̆ғы́], [а°wы̆рлы̆ғы́], [ты̆ны́ч], [йа°фра́қ].

**3.** Тексттан тап һәм укы:

— керпенең энәләре турында;
— керпенең туклануы турында.

**4.** Текстны файдаланып, керпе турында яз.

Керпенең энәләре саны ... .
Энәләрнең озынлыгы ... .
Керпенең буе ... .
Керпенең авырлыгы ... .
Керпе ... ашый.
Керпе кыш көне ... .

**5.** Иптәшеңә керпе турында нинди сораулар бирә аласың?

**6.** Диалогны өйрән, иптәшең белән сөйләшеп кара.

— Оля, тыңла әле, яңалык әйтәм.
— Нәрсә булды?
— Мин кичә бакчада керпе күрдем.
— Тоттыңмы соң?
— Әйе, өйгә алып кердем.
— Ничек тоттың? Ул бит энәле.
— Сөлге белән тоттым. Өйдә сөт бирдем, ләкин ул эчми. Диван астында утыра да утыра.
— Наташа, син аны җибәр. Аның балалары бардыр. Ул сезнең бакчага алар өчен азык эзләп килгән, бакчада тычканнар күп.
— Ярар, Оля, син дөрес әйтәсең, рәхмәт сиңа.

**7.** Как скажешь о том, что:

— ты увидел ёжика;
— он ещё маленький;
— ёжик испугался;
— ты принёс его домой?

## 70—71 нче дәресләр

### Проверь себя!

**1.** Нокталар урынына кирәкле хәрефләрне яз.

Ар...сл...н, б...р... , ф...л, д...я, т...шб...к... , керп... , ти...н, а... , т...лк... , к...ян.

**2.** Заполни таблицу.

Сыер, сарык, төлке, бүре, эт, кәҗә, арыслан, юлбарыс, фил, леопард, ат, куян, дөя.

| Кыргый хайваннар | Йорт хайваннары |
|---|---|
| ... | ... |

**3.** Сүзләрдән җөмләләр төзе.

1. Керпе, йоклый, кыш көне.
2. Бөҗәкләр, тычкан, гөмбә, җиләк, ашый, керпе.
3. Бакчада, мин, күрдем, керпе.
4. Бирдем, мин, сөт, керпегә.
5. Урманга, мин, җибәрдем, керпене.

**4.** Җөмләләрдән сыйфатларны тап, дәрәҗәләрен билгелә.

1. Ак куян зур, соры куян зуррак. 2. Төлке усал, ә бүре усалрак. 3. Аю әкрен йөгерә, бүре тиз йөгерә, ә куян бик тиз йөгерә.

**5.** Нокталар урынына сыйфатлар өстәп әйт.

Арыслан … , фил … , куян … , бүре … , дөя … , аю … , тиен … , ташбака … , керпе … , төлке … .

**6.** Сүзләрне тәрҗемә ит.

озын — …
озынлык — …

авыр — …
авырлык — …

**7.** Ребусны чиш. Җәнлекләр турында сөйлә.

1)



2)



**8.** Җөмләләр төзе.

Бүре
Тиен
Керпе
Фил
Аю
Куян

?

чикләвек
ипи
сөт
бал
ит
кишер

ярата.

# КЫШКЫ УЕННАР

## 72—73 нче дәресләр

**1.** Шигырьне укы.



**Беренче кар**

Йомшак кына кар яуды.
Бөтен җирне каплады:
Ап-ак булды болыннар,
Ап-ак булды киң кырлар.

Әхмәт Ерикәй

**2. Исеңә төшер!**

**Сыйфатларның артыклык дәрәҗәсе**
**Превосходная степень прилагательных**

**бик зур** — очень большой
**иң матур** — самый красивый
**ямь-яшел** — зелёный-презелёный
**ап-ак** — белый-пребелый
**кып-кызыл** — красный-прекрасный

**3.** Шигырьдән сыйфатларны тап, дәрәҗәсен билгелә.

**4.** Сүзләрне дөрес укырга өйрән, тәрҗемәсен тап.

[қа°р], [йа°фра́қ], [са°лқы́н], [туңа́], [төн], [қо̆йа́ш], [боз], [қысқара́], [җылы́ йа°қ].

**5. Исеңә төшер!**

В этих словах ударение падает на первый слог:

| | |
|---|---|
| **нә́рсә?** — что? | **ни́нди?** — какой? |
| **ка́йда?** — где? | **ни́чек?** — как? |
| **ка́я?** — куда? | **ка́йчан?** — когда? |
| **ка́йдан?** — откуда? | **ни́шли?** — что делает? |

**6.** 5нче күнегүдәге сораулар белән җөмләләр уйла.

**7.** Сүзләрнең антоним парларын тап.

| | ? | |
|---|---|---|
| төн | | салкын |
| кара | | астында |
| өстендә | | озын |
| кыска | | көн |
| җылы | | ак |

**8.** 7нче күнегүдәге сүзләргә сораулар куй, алар белән җөмләләр төзе.

**9.** Син кыш билгеләрен (признаки) онытмадыңмы? Кайсы билгеләр туры килә (подходят)? Дәфтәреңә яз.

Салкын, яфраклар коела, яңгыр ява, кар ява, салкын җил, җир ап-ак, елгада су туңа, көннәр кыскара, көчле бураннар була, төннәр кыскара, кошлар җылы якка китәләр, елгаларны боз каплый, кояш кыздыра.

**10.** Син ел фасылларының билгеләрен беләсеңме? Рәсемнәргә карап, бер-берегезгә сораулар бирегез.









**11.** Кыш билгеләре турында сөйләргә өйрән.

## 74—76 нчы дәресләр

**1.** Бу сүзләрне дөрес әйтергә өйрән. Алар бик матур бер хикәя укырга ярдәм итәр.

[а́°п̄ак̦], [ма°лайла́р], [йомша́к̦], [йа°сы́йлар], [зурайа́], [ша°тлана́], [күң̦э̆л̄э́], [кишэ́р], [к̦а°р ба°ба́й], [күмэ́р], [бо̆ро́н], [бэ̆ргә́].

**2.** Җөмләләрне дәвам ит.

1. Олег урамга ... .
2. Олег урамда ... .
3. Олег урамнан ... .

**3.** Фигыльләрне күплек санда әйт.

Ява, чыга, ясый, шатлана, куя.

**4.** Хикәяне укы. Малайларга ни өчен рәхәт?

### Кышкы уен

Урамда ап-ак кар ява. Олег урамга чыкты. Урамда малайлар уйныйлар. Йомшак кардан шар ясыйлар. Ап-ак кар зурая бара. Балалар шатланалар.

— Ай-яй, нинди матур булды!

Малайлар кардан ак аю һәм кар бабай ясап куялар. Аларга күңелле.

— Кар бабайның күзенә күмер куябыз.

— Борын да ясыйк. Борыны кызыл булсын.

Айнур өйдән кишер алып чыга. Кар бабайга кишердән борын ясыйлар. Бергә уйнау бик күңелле.

Госман Бакирдан

**күмер** — уголь
**зурая** — увеличивается

**5.** Җөмләләрне хикәя эчтәлеге тәртибендә урнаштыр (расположи предложения в последовательности содержания рассказа).

Йомшак кардан шар ясыйлар. Урамда ап-ак кар ява. Малайлар кардан ак аю һәм кар бабай ясыйлар. Бергә уйнау бик күңелле. Кар бабайның күзенә күмер, борын итеп, кишер куялар.

**6.** Син кар бабай ясый беләсеңме? Ике баганадагы сүзләрдән җөмләләр төзе.

| | | |
|---|---|---|
| кар | | кишер куям |
| башына | **?** | башлык ясыйм |
| борынына | | күмер куям |
| күзләренә | | тәгәрәтәм |

**7.** Малайлар кар бабайны ничек ясыйлар? Рәсемгә кара, сөйләп бир.



**8.** Кайсы диалогның эчтәлеге хикәягә туры килә? Дустың белән сөйләш.

1. — Олег, әйдә урамга чыгабыз.
— Ә урамда рәхәтме?
— Рәхәт. Ап-ак кар ява.
— Чаңгы шуабызмы?
— Юк, кар бабай ясыйбыз.

2. — Олег, сез урамда нишлисез?
— Уйныйбыз, кар бабай, ак аю ясыйбыз.
— Кар бабайны ничек ясыйсыз?
— Кардан шар тәгәрәтеп.

3. — Костя, әйдә урамга чыгабыз.
— Урамда нишлибез?
— Чаңгы шуабыз.
— Минем чаңгым юк, чанам бар.
— Алайса чана шуабыз.

## 77—78 нче дәресләр

**1.** **Исеңдә калдыр!**

**быел** — в этом году
**иске ел** — старый год
**былтыр** — в прошлом году
**яңа ел** — новый год
**кичә** — вчера
**бүген** — сегодня



**2.** Шигырьне укы. Шигырьдә сүз нинди көн турында бара?

**Яңа ел килгәч**

Апа былтыр киткән иде,
Быел кайтты ёлкадан.
Ә мин былтыр яткан идем,
Быел тордым йокыдан.

Иске елны ертып ташлап,
Яңа елны башладык.
Былтыр пешкән бәлешләрне
Быел тагын ашадык.

Кичә мин биш яшьтә идем,
Бүген инде алтыда.
Яшем артты, акыл нишләр?
Артыр әле ансы да.




Бари Рәхмәт

**3.** Җөмләләрне укы. Нокталар урынына тиешле сүзләрне куй.

1. Апа ёлкага ... китте, ... кайтты. 2. Мин ... йокларга яттым, ... тордым. 3. ... бәлеш пешердек, ... ашадык. 4. Мин ... биш яшьтә идем, ... миңа алты яшь.

**4.** Сорауларга җавап бир.

1. Шигырьдә нинди көн турында сүз бара?
2. Бәлешне кайчан пешергәннәр?
3. Бәлешне кайчан ашаганнар?
4. Календарьның кайсы битен ертып ташлаганнар?

**5.** Сүзләрнең антоним парларын тап.

| | | |
|---|---|---|
| быел — ... | иске ел — ... | рәхәт — ... |
| бүген — ... | яхшы — ... | зур — ... |

**6.** Син Яңа ел бәйрәме турында бик күп шигырьләр, җырлар өйрәнәсең. Шул җырларны (шигырьләрне) исеңә төшер.

1. Чыршы, чыршы, без сине
Сагынып көттек ел буе,
Син тагын да матуррак
Бизәлгәнсең бу юлы.

Сәхаб Урайский

2. Тышта буран бөтен җиргә
Карлар тутыра.
Безнең бүлмәдә ямь-яшел
Чыршы утыра.

Җәвад Тәрҗеманов

**7.** Диалогка төшеп калган җөмләләрне өстә. Иптәшең белән сөйләш.

— Аня, мәктәптә чыршы бизәдегезме?
— ... .
— Яңа ел бәйрәме кайчан башлана?
— Бәйрәм сәгать икедә башлана.
— ... ?
— Бәйрәмгә ак күлмәк киям, ә син нәрсә киясең?
— ... .
— Мин шигырь сөйлим, ә син?
— ... .

**8.** Бәйрәм сәгать ничәдә башлана?









**9.** Сораулар буенча партадашың белән сөйләш.

1. Син Яңа ел бәйрәменә кайчан барасың?
2. Бәйрәм сәгать ничәдә башлана?
3. Бәйрәмгә кем белән барасың?
4. Син бәйрәмдә нишлисең?
5. Син Яңа елны кайда каршылыйсың?
6. Бәйрәм көнне нәрсә пешерәсез?

**10.** «Безнең мәктәптә Яңа ел бәйрәме» темасына хикәя төзе.

**11.** Яңа ел турында бер шигырьне яттан сөйләргә өйрән.

## 79 нчы дәрес

**1.** Рәсемнәргә кара һәм әйт: карнавалга кемнәр килгән? Алар баш киемнәрен дөрес кигәннәрме?



**2.** Текстны укы һәм әйт: төрле илләрдә (в разных странах) Яңа елны ничек бәйрәм итәләр?



Вьетнамда Яңа елны каршылаганда нинди дә булса агач утырталар. Португалиядә сәгать төнге 12дә виноград

ашыйлар. Бразилиядә борчак ашы пешерәләр. Грециядә, алтын-көмеш акча салып, торт пешерәләр. Акча кемгә эләгә, шул бәхетле була. Австралиядә Яңа елны җәй көне каршылыйлар. Балалар диңгез яры буенда комнан төрле сарайлар төзиләр.

